для предоставления государственных услуг. Это подтверждается также принятым в соответствии со статьей 12 указанного выше Федерального закона приказом Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан от 19 ноября 2014 года № 639, которым утвержден Административный регламент предоставления государственной услуги по назначению компенсации части родительской платы за присмотр и уход за ребенком в образовательных организациях, реализующих образовательную программу дошкольного образования, устанавливающий стандарт и порядок предоставления государственной услуги по назначению компенсации.

Определяя требования к взаимодействию с заявителем при предоставлении государственных услуг, Федеральный закон «Об организации предоставления государственных и муниципальных услуг» предусматривает, что органы, предоставляющие государственные услуги, не вправе требовать от заявителя представления документов и информации, которые находятся в распоряжении органов, предоставляющих государственные услуги, иных государственных органов либо подведомственных государственным органам организаций, участвующих в предоставлении государственных услуг, в соответствии с нормативными правовыми актами Российской Федерации, нормативными правовыми актами субъектов Российской Федерации (пункт 2 части 1 статьи 7).

Устанавливая данный запрет, федеральный законодатель тем не менее предусмотрел исключение в отношении отдельных документов, которые в силу части 6 указанной выше статьи не могут быть истребованы в порядке межведомственного взаимодействия. Применительно к предмету рассматриваемого дела к числу таких документов относятся: свидетельства о государственной регистрации актов гражданского состояния; документы, связанные с прохождением обучения, выдаваемые организациями, осуществляющими образовательную деятельность; документы, подтверждающие право гражданина на получение социальной поддержки.

Следует отметить, что исключение аналогичного характера установлено и в отношении запрета требовать от заявителей осуществления действий, в том числе согласований, необходимых для получения государственных услуг и связанных с обращением в иные государственные органы, органы местного самоуправления, организации. Согласно взаимосвязанным положениям пункта 3 части 1 статьи 7 и пункта 2 части 1 статьи 9 указанного Федерального закона такое исключение закреплено, в частности, в отношении услуг, включенных в утверждаемые нормативным правовым актом субъекта Российской Федерации перечни услуг, которые являются необходимыми и обязательными для предоставления исполнительными органами государственной власти субъекта Российской Федерации государственных услуг.

В Республике Татарстан Перечень услуг, которые являются необходимыми и обязательными для предоставления исполнительными органами государственной власти Республики Татарстан

государственных услуг и предоставляются организациями, участвующими в предоставлении государственных услуг, утвержден постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 13 августа 2011 года № 675. В указанный Перечень включены в том числе услуги по выдаче организациями, осуществляющими образовательную деятельность, справок и иных документов.

Следовательно, определив в оспариваемой норме документы, в том числе копию договора об устройстве ребенка в соответствующую образовательную организацию, копию квитанции на оплату за присмотр и уход за ребенком в образовательной организации, которые должны быть в обязательном порядке представлены законным представителем (родителем, усыновителем, опекуном) в отделение Республиканского центра материальной помощи (компенсационных выплат) для получения компенсации, Кабинет Министров Республики Татарстан руководствовался вышеназванными нормами федерального и республиканского законодательства и не установил какие-либо дополнительные необоснованные требования, препятствующие реализации права на получение законодательно установленной гарантии на выплату компенсации.

3.2. В силу части второй статьи 68 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционный суд Республики Татарстан принимает решение по делу, оценивая как буквальный смысл рассматриваемого акта, так и смысл, придаваемый ему сложившейся правоприменительной практикой, а также исходя из его места в системе нормативных правовых актов. На этом основании конституционность оспариваемой нормы Положения с точки зрения ее правоприменения следует оценивать во взаимосвязи с иными нормативными правовыми актами, имеющими отношение к данному вопросу, в частности с Административным регламентом предоставления государственной услуги по назначению компенсации части родительской платы за присмотр и уход за ребенком в образовательных организациях, реализующих образовательную программу дошкольного образования (далее — Административный регламент).

Анализ норм Административного регламента (в редакции, действовавшей на момент обращения гражданки Л.В. Кирюшиной с заявлением о назначении компенсации) указывает на то, что им, по сравнению с оспариваемым пунктом 8 Положения, установлен более широкий перечень документов, получаемых в рамках межведомственного взаимодействия. Так, в соответствии с пунктом 2.5 Административного регламента заявителю, не имеющему детей в возрасте от 18 до 23 лет, обучающихся по очной форме обучения, при личном обращении достаточно было представить заявление. При этом иные документы, в том числе предусмотренные обжалуемым пунктом 8 Положения, в силу пункта 2.6 Административного регламента подлежали получению в рамках межведомственного взаимодействия и их непредставление заявителем не могло являться основанием для отказа в предоставлении данной услуги.

Приказом Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан от 12 октября 2015 года № 730 Административный регламент изложен в новой редакции. Тем не менее и в ныне действующей редакции Административного регламента перечни документов, которые должны быть представлены заявителем для получения данной услуги, а также документов, получаемых в порядке межведомственного взаимодействия, не совпадают с перечнем документов, предусмотренных оспариваемым пунктом 8 Положения.

Вместе с тем в силу части 6.1 статьи 7 Федерального закона «Об организации предоставления государственных и муниципальных услуг» получение документов в порядке межведомственного взаимодействия на уровне субъектов Российской Федерации, кроме случаев, прямо предусмотренных федеральным законом, возможно лишь тогда, когда это предусмотрено законом субъекта Российской Федерации или нормативным правовым актом высшего исполнительного органа государственной власти субъекта Российской Федерации.

В этой связи установленное Административным регламентом регулирование, выходящее за рамки оспариваемого Положения, не согласуется как с приведенными нормами Федерального закона «Об организации предоставления государственных и муниципальных услуг», так и с конституционными принципами правового государства и верховенства закона в целом, в том числе с положением статьи 29 (часть третья) Конституции Республики Татарстан, в силу которого порядок осуществления, охраны и защиты конституционных прав и свобод устанавливается законами.

Исходя из этого, Конституционный суд Республики Татарстан отмечает, что Административный регламент как в действующей редакции, так и в редакции, утратившей силу, не является надлежащим нормативным правовым актом, который может определить какие-либо дополнительные основания для принятия решения о назначении или об отказе в назначении компенсации части родительской платы. Однако данный ведомственный нормативный правовой акт в силу статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не может быть предметом рассмотрения Конституционного суда Республики Татарстан по жалобам граждан.

3.3. В соответствии с Конституцией Республики Татарстан каждый имеет право на неприкосновенность частной жизни, личную и семейную тайну, защиту своей чести и доброго имени (статья 36, часть первая).

Отношения, связанные с обработкой персональных данных, осуществляемой в том числе органами государственной власти субъектов Российской Федерации, иными государственными органами и органами местного самоуправления, регулируются Федеральным законом от 27 июля 2006 года № 152-ФЗ «О персональных данных» (в редакции Федерального закона от 25 июля 2011 года № 261-ФЗ). В соответствии с частью 1 статьи 9 данного

Федерального закона субъект персональных данных принимает решение о предоставлении его персональных данных и дает согласие на их обработку свободно, своей волей и в своем интересе; согласие на обработку персональных данных должно быть конкретным, информированным и сознательным; согласие на обработку персональных данных может быть дано субъектом персональных данных или его представителем в любой позволяющей подтвердить факт его получения форме, если иное не установлено федеральным законом.

Условия обработки персональных данных определены статьей 6 этого же Федерального закона. К таким условиям относятся, в частности, согласие субъекта персональных данных на обработку его персональных данных, а также необходимость исполнения полномочий исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации и функций организаций, участвующих в предоставлении государственных услуг, предусмотренных Федеральным законом «Об организации предоставления государственных и муниципальных услуг».

Из буквального содержания приведенной нормы следует, что указанные условия не находятся во взаимосвязи и каждое из них является самостоятельным основанием обработки персональных данных. Более того, часть 2 статьи 9 Федерального закона «О персональных данных» напрямую связывает предоставление государственных услуг гражданам с обработкой их персональных данных, поскольку предусматривает, что в случае, когда обработка персональных данных необходима для исполнения функций организаций, участвующих в предоставлении государственных услуг, оператор вправе продолжить обработку данных даже тогда, когда субъект персональных данных отзывает свое согласие на их обработку. Иными словами, при обращении за получением государственных услуг согласие заявителя на обработку его персональных данных не является обязательным условием для их получения. При таких обстоятельствах Конституционный суд Республики Татарстан приходит к выводу, что, обращаясь за получением государственной услуги по назначению компенсации части родительской платы и прилагая необходимые для этого документы, получатель государственных услуг фактически уже выражает согласие на передачу и обработку своих персональных данных, требуемых для предоставления данной услуги.

Следовательно, нормы пункта 8 Положения не должны пониматься в правоприменительной практике как допускающие возможность отказа в предоставлении государственной услуги по назначению компенсации части родительской платы за присмотр и уход за ребенком в образовательных организациях, реализующих образовательную программу дошкольного образования, в случае отсутствия отметки гражданина о согласии на обработку его персональных данных в заявлении, предоставляемом им для получения такой государственной услуги.

Таким образом, пункт 8 Положения в системе действующего правового регулирования, с учетом выявленного в настоящем по-

становлении конституционно-правового смысла, по своему характеру и публично-правовому предназначению является одним из элементов механизма, направленного на обеспечение мер по реализации гражданами их права на социальную защиту со стороны государства с соблюдением принципа адресности при предоставлении мер социальной поддержки, сам по себе не может рассматриваться как отменяющий, ограничивающий или иным образом нарушающий конституционные права граждан, в том числе заявительницы, и тем самым не противоречит Конституции Республики Татарстан.

Проверка же законности и обоснованности обстоятельств, послуживших причиной для отказа гражданке Л.В. Кирюшиной в приеме заявления о назначении компенсации, в том числе ввиду отсутствия ее письменного согласия на обработку персональных данных, предполагает установление фактических обстоятельств дела, что не входит в компетенцию Конституционного суда Республики Татарстан, поскольку в силу части девятой статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционный суд Республики Татарстан решает исключительно вопросы права и при осуществлении конституционного судопроизводства воздерживается от установления и исследования фактических обстоятельств во всех случаях, когда это входит в компетенцию других судов или иных органов государственной власти Республики Татарстан.

4. Признание оспариваемого заявительницей пункта 8 Положения соответствующим Конституции Республики Татарстан не препятствует совершенствованию порядка обращения за компенсацией части родительской платы за присмотр и уход за ребенком в образовательных организациях, реализующих образовательную программу дошкольного образования.

В силу части 6.1 статьи 7 Федерального закона «Об организации предоставления государственных и муниципальных услуг» законодатель субъекта Российской Федерации или высший исполнительный орган государственной власти субъекта Российской Федерации вправе установить собственное правовое регулирование, при котором документы, представляемые в настоящее время гражданином самостоятельно и необходимые для предоставления государственных услуг исполнительными органами государственной власти субъекта Российской Федерации, могут быть получены в ходе межведомственного взаимодействия.

С целью обеспечения единообразного подхода в определении исчерпывающего перечня документов и информации, подлежащих представлению гражданином самостоятельно, и документов, подлежащих получению в рамках межведомственного взаимодействия, а также учитывая наличие правовых и технических условий для совершенствования системы межведомственного информационного взаимодействия в рамках оказания государственных услуг в Республике Татарстан, Правительство Республики Татарстан в пределах своих дискреционных полномочий, основанных на соответствующих положениях федерального зако-

нодательства, вправе расширить перечень документов, подлежащих получению в порядке межведомственного взаимодействия.

На основании изложенного, руководствуясь статьей 6, частями первой и второй статьи 66, частями первой, второй и шестой статьи 67, статьями 68, 69, 71 и 73, пунктом 1 части первой статьи 104 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**постановил:**

1. Признать пункт 8 Положения о порядке обращения за компенсацией части родительской платы за присмотр и уход за ребенком в образовательных организациях, реализующих образовательную программу дошкольного образования, и порядке ее выплаты, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 января 2007 года № 9 «О компенсации части родительской платы за присмотр и уход за ребенком в образовательных организациях, реализующих образовательную программу дошкольного образования» (в редакции постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 21 мая 2014 года № 338), соответствующим Конституции Республики Татарстан.

2. Настоящее Постановление окончательно, не подлежит обжалованию, вступает в силу немедленно после его провозглашения, действует непосредственно и не требует подтверждения другими органами и должностными лицами.

3. Согласно статье 72 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» настоящее Постановление подлежит незамедлительному опубликованию в газетах «Ватаным Татарстан» и «Республика Татарстан». Постановление должно быть опубликовано также в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 68-П

Конституционный суд
Республики Татарстан

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИСЕМЕ БЕЛӘН

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

**гражданка Л.В. Кирюшина шикаятенә бәйле рәвештә «Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыра торган мәгариф оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 21 маендагы 338 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыра торган мәгариф оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация алу буенча мөрәҗәгать итү һәм аны түләү тәртибе турындагы нигезләмәдәге аерым нормаларның конституциячелләген тикшерү турындагы эш буенча**

2016 ел
27 май
Казан шәһәре

# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында «Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыра торган мәгариф оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 21 маендагы 338 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыра торган мәгариф оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация алу буенча мөрәҗәгать итү һәм аны түләү тәртибе турындагы нигезләмәдәге аерым нормаларның конституциячелләген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданка Л.В. Кирюшинаның шикаяте сәбәп булды. Дәгъва белдерелә торган Нигезләмәдәге 8 пунктның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья А.Р. Шакараев мәгълүматын, яклар — гражданка Л.В. Кирюшина, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкилләре — Татарстан Республикасының хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Н.В. Бутаева, Татарстан Республика-

сы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының юридик бүлеге башлыгы Р.Г. Миңнеголов аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең закон проектлары эшләү бүлеге баш киңәшчесе Л.К. Вәлиуллинаның, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы М.Б. Сөнгатуллинның, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Хокук идарәсенең административ хокук һәм законнарны системалаштыру бүлекчәсе мөдире Д.Н. Латыйпованың, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы Э.С. Каминскийның, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Арбитраж судының суд практикасын анализлау һәм гомумиләштерү бүлеге башлыгы урынбасары Т.Р. Гыйззәтовның, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы прокуратурасы Федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге башлыгы А.Р. Вәлиәхмәтовның, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге башлыгы урынбасары Р.И. Сәйфетдинованың чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Л.В. Кирюшина «Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыра торган мәгариф оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 21 маендагы 338 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыра торган мәгариф оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация алу буенча мөрәҗәгать итү һәм аны түләү тәртибе турындагы нигезләмәнең (алга таба шулай ук — Нигезләмә) 8 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъвалана торган норма нигезендә белем бирү оешмасы белән шартнамә төзегән һәм мәктәпкәчә белем бирү буенча төп белем бирү программасын тормышка ашыра торган тиешле белем бирү оешмасына баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана

түләвен керткән законлы вәкил (ата яки ана, уллыкка (кызлыкка) алучы, опекун) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыра торган мәгариф оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация (алга таба — компенсация) билгеләү һәм аны түләү өчен Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге бүлегенә Татарстан Республикасы территориясендәге яшәү (тору) урыны буенча, ә Татарстан Республикасы территориясендә теркәлмәгән гражданнар өчен — тиешле мәгариф оешмасы теркәлгән урын буенча гариза һәм түбәндәге документларны тапшыра: компенсация билгеләнә торган баланың туу турында таныклыгы күчермәсе (әгәр күчермә нотариуста таныкланмаса, төп нөсхәсе белән бергә); Нигезләмәнең 5 пункты нигезендә гариза бирүче гаиләсе составында исәпкә алынган, компенсация билгеләнә торган балага кадәр туган балаларның туу (уллыкка, кызлыкка алыну) турындагы таныклыклары күчермәләре; балага (балаларга) мөнәсәбәттә бер ата-ана (ата-аналар) ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән очракта суд карары; баланы тиешле мәгариф оешмасына урнаштыру турында килешү күчермәсе; компенсацияне банк аша алганда, мәгариф оешмасы белән килешү төзегән затның банктагы шәхси счеты номеры; белем бирү оешмасында баланы караштырып торган һәм караган өчен түләүгә квитанция күчермәсе; белем бирү оешмасыннан 18 яшьтән 23 яшькә кадәрге балаларның көндезге формада белем алуы турындагы белешмә кәгазе.

Гражданка Л.В. Кирюшинаның шикаятеннән һәм Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында ясаган чыгышыннан аңлашылганча, аның улы М.Р. Кирюшин — инвалид һәм компенсацияләү төрендәге балалар бакчасына йөри. 2015 елның июнь аенда ханым Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Совет районы буенча бүлегенә балалар бакчасында баласын караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация алу турында гариза белән мөрәҗәгать иткән. Әмма компенсация билгеләү турындагы гаризаны кабул итүдән баш тартканнар, чөнки ул Нигезләмәнең 8 пункты белән билгеләнгән документларның тулы пакетын, шул исәптән баланы балалар бакчасына урнаштыру турында килешү күчермәсен тапшырмаган, шулай ук гаризасында шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкны күрсәтмәгән булган.

Гражданка Л.В. Кирюшина билгеләгәнчә, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары һәм алар ведомствосындагы оешмалар «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон күрсәтмәләре нигезендә гариза бирүчедән башка ведомстволар карамагында булган документлар һәм мәгълүмат бирүне таләп итәргә хокуклы түгел. Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, әлеге мәгълүматларны Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре күрсәтелгәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек (алга таба шулай ук — ведомствоара хезмәттәшлек) тәртибендә запрослар җибәрү юлы белән алырга мөмкин. Моңа

бәйле рәвештә гражданка Л.В. Кирюшина Нигезләмәнең 8 пункты ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә алынырга мөмкин булган документларны тапшыру бурычын гражданнарга хокуксыз йөкли дип уйлый.

Мөрәҗәгать итүче дәгъвалана торган нормадагы билгесезлекне булган хокук куллану практикасының компенсация билгеләү турындагы гаризаны анда шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык хакында тамга булмаган очракта кабул итүдән баш тартуга мөмкинлек бирүдә дә күрә. Аның фикеренчә, Нигезләмәнең 8 пункты, үзендәге сүзгә-сүз мәгънәсеннән чыгып, гражданнан андый ризалык алу кирәклеге турында таләп билгеләми.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Л.В. Кирюшина Татарстан Республикасы Конституция судыннан китерелгән хокукый җайга салуны Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче һәм икенче өлешләр), 30, 38 (беренче һәм өченче өлешләр), 54 (беренче өлеш) һәм 103 статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре — иң зур хәзинә; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау — Татарстан Республикасының бурычы; Татарстан Республикасы — сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген социаль хәленә һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең теләсә кайсы рәвеше тыела; Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен дәүләт тарафыннан яклауның тигез хокукы гарантияләнә; гражданнар шәхси, социаль-икътисади хокукларның һәм ирекләрнең бөтен тулылыгына ия; гаилә, ана булу һәм балачак дәүләт яклавында; дәүләт гаилә турында, ананың һәм баланың сәламәтлеген тәэмин итү һәм балаларны тәрбияләү турында кайгырта; һәркемгә гарипләнгән очракта, балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Конституциясенең, Татарстан Республикасы Конституциясенең, федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үтәлешен тәэмин итә, карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара, аларның үтәлешен тикшерә.

1.1. Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында гражданка Л.В. Кирюшина шикаять предметына төгәллек кертте һәм карала торган Нигезләмәдәге компенсациянең барлык кирәкле документлары белән гаризаны тапшырган айдан башлап билгеләнүен һәм түләнүен күздә тота торган 10 пунктның конституциячеллеген дә тикшерүне сорады. Аның фикеренчә, компенсация шартсыз характерга ия һәм аны алуга хокук мәктәпкәчә белем бирү буенча төп белем бирү программасын тормышка ашы-

ра торган тиешле белем бирү оешмасына баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвен ата яки ана (законлы вәкил) керткән вакыттан гамәлгә ашырылырга тиеш.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгегә игътибар итә: Нигезләмәнең 10 пункты билгеләгән җайга салу компенсация алу хокукын гамәлгә ашыруга юнәлгән, мөрәҗәгать итү характерына ия һәм аны алуга хокуклы гражданнардан аерым гамәлләр кылуны таләп итә. Үзенең хокукый табигате буенча әлеге норма гражданнарның компенсация алуга хокукын гамәлгә ашыру механизмын беркетеп, шул исәптән аны билгеләү һәм түләү тәртибен раслап, гражданнарның компенсация алуга хокукын гамәлгә ашыру мөмкинлеген шик астына куймый һәм гражданнарның конституциячел хокукларын боза торган итеп карала алмый, һәм, димәк, аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Суды практикасына туры килә, аның буенча гражданнарга социаль ярдәм чараларын билгеләү өчен теләсә кайсы вакытта аларга хокук барлыкка килгәннән соң мөрәҗәгать итү мөмкинлеген бирә торган, шулай ук күрсәтелгән чаралар билгеләнә башлаган вакытларны билгели һәм гражданнарга аларны билгеләү турында гариза белән мөрәҗәгать итү бурычын йөкли торган норматив җайга салу социаль тәэминатка хокукны киртәләрсез гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә юнәлгән, гражданга әлеге хокукны тормышка ашыру (тормышка ашырудан баш тарту) буенча гамәлләр иреге бирә, социаль ярдәм чараларын билгеләү өчен вакытында мөрәҗәгать итәргә булышлык итә һәм ул үзеннән-үзе гражданнарның нинди дә булса хокукларын боза торган итеп карала алмый (2005 елның 24 мартындагы 76-О номерлы; 2006 елның 17 октябрендәге 380-О номерлы һәм 2014 елның 29 маендагы 1100-О номерлы билгеләмәләр).

Моннан тыш, әлеге нигезләмәнең конституциячеллегенә дәгъва белдереп, мөрәҗәгать итүче фактта компенсацияне Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге бүлегенә мөрәҗәгать итү моментыннан түгел, ә мәгариф оешмасында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвен кертү моментыннан билгеләү кирәклеге турында мәсьәлә куя. Ләкин әлеге мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дискрецион вәкаләтләренә керә.

Шулай итеп, гражданка Л.В. Кирюшина шикаяте Нигезләмәдәге 10 пунктның конституциячеллеген тикшерү өлешендә карауга кабул ителә алмый, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының шикаять бирелергә мөмкин дигән таләпләренә җавап бирми, ә анда куелган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

1.2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы өченче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә

күрсәтелгән орган актының конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карарлар кабул итә.

Шулай итеп, «Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыра торган мәгариф оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 21 маендагы 338 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыра торган мәгариф оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация алу буенча мөрәҗәгать итү һәм аны түләү тәртибе турындагы нигезләмәнең 8 пункты әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора, чөнки аның нигезләмәләрендә — аларга булган хокук куллану практикасы белән салынган мәгънә буенча — билгесезлек шул дәрәҗәдә ки, алар билгеләгән документлар законлы вәкил (ата яки ана, уллыкка (кызлыкка) алучы, опекун) тарафыннан мәҗбүри рәвештә тапшырылырга тиеш, ә компенсация билгеләү турындагы гаризада аның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык хакында тамга булырга тиеш.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган хокукый норма тәрбия, мәгариф буенча гомуми мәсьәләләргә, шулай ук социаль яклау өлкәсенә кагыла, алар Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында (72 статья, 1 өлешнең «е» һәм «ж» пунктлары). Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителүче законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килә алмый (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы, 2 һәм 5 өлешләр).

Дәгъвалана торган норматив хокукый актны кабул итү моментына «Мәгариф турында» 1992 елның 10 июлендәге 3266-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (2006 елның 5 декабрендәге 207-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) гамәлдә булган, аның 52.2 статьясы нигезләмәләре белән шул күздә тотылган булган: мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган дәүләт һәм муниципаль мәгариф учреждениеләренә йөрүче балаларны тәрбияләүгә материаль ярдәм күрсәтү максатларында ата-аналарга (законлы вәкилләргә) ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация түләнә; компенсация алу өчен мөрәҗәгать итү тәртибе, шулай ук аны түләү тәртибе Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнә.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү

программасын тормышка ашыручы дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында баланы тәрбияләп тоткан өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы карарын кабул итеп, үзенә федераль законнар нигезендә бирелгән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең үзара бәйләнештә булган 102 (4 пункт) һәм 103 статьялары нигезләмәләренә таянган вәкаләтен законлы рәвештә гамәлгә ашырган.

3. Татарстан Республикасы Конституциясе Татарстан Республикасын социаль дәүләт дип игълан итеп (13 статья), шуны беркетә: гаилә, ана булу һәм балачак дәүләт яклавында, дәүләт гаилә турында, ананың һәм баланың сәламәтлеген тәэмин итү һәм балаларны тәрбияләү турында кайгырта (38 статья, беренче һәм өченче өлешләр); һәркемгә шул исәптән балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә (54 статья, беренче өлеш). Мәгънәләре буенча тиңдәш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясе, шул исәптән аның 7, 38 (1 өлеш) һәм 39 (1 өлеш) статьялары белән билгеләнгән.

Әлеге конституциячел нормалар 1996 елның 3 маендагы Европа социаль хартиясенең (яңадан каралганының) 16 статьясы нигезләмәләренә туры килеп тора, аларда күздә тотылганча, җәмгыятьнең төп күзәнәге буларак гаиләнең бар яктан да үсеш алуы өчен кирәкле шартлар белән тәэмин итү максаты белән яклар гаилә тормышын икътисади, хокукый һәм социаль яклауга, аерым алганда, социаль һәм гаилә пособиеләре, салым ташламалары, гаиләгә торак бирү, яшь гаиләләргә ярдәм һәм башка тиешле чаралар аша ярдәм итүне үз өсләренә алалар.

3.1. Россия Федерациясенең мәгариф өлкәсендәге дәүләт сәясәтенең төп принциплары, мәгариф системасының эшләп торуының һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруның гомуми кагыйдәләре хәзерге вакытта «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән, аның 65 статьясы нигезләмәләре буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешманы гамәлгә куючы баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-анадан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүне (алга таба — ата-ана түләве) һәм аның күләмен билгели. Әлеге статьяның 5 өлеше нигезендә мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмаларына йөрүче балаларны тәрбияләүгә һәм укытуга матди ярдәм итү максатларында ата-ана түләвен керткән ата-анага (законлы вәкилләргә) компенсация алуга хокук бирелә. Компенсация алу өчен мөрәҗәгать итү тәртибе һәм аны түләү тәртибе Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнә, ә компенсацияне түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәсе булып санала (6 һәм 7 өлешләр).

Татарстан Республикасында компенсация алуга хокук «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татар-

стан Республикасы Законының 21 статьясында билгеләнгән, аның нигезендә әлеге компенсация ата-анага (законлы вәкилләргә) өстәмә социаль ярдәм чарасы булып тора, Татарстан Республикасы бюджеты хисабына финанслана, ә аны алу тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Нигезләмәнең 7 пункты буенча компенсация белем бирү оешмасы белән шартнамә төзегән һәм мәктәпкәчә белем бирү буенча төп белем бирү программасын тормышка ашыра торган тиешле белем бирү оешмасына баланы тәрбияләп тоткан өчен ата-ана түләвен керткән законлы вәкилгә (атага яки анага, уллыкка (кызлыкка) алучыга, опекунга) (алга таба — законлы вәкил) билгеләнә һәм түләнә. Компенсация алу өчен законлы вәкил Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге бүлегенә Татарстан Республикасы территориясендәге яшәү (тору) урыны буенча, ә Татарстан Республикасы территориясендә теркәлмәгән гражданнар өчен — тиешле мәгариф оешмасы теркәлгән урын буенча гариза һәм Нигезләмәнең дәгъвалана торган 8 пунктында каралган документлар тапшыра. Нигезләмәнең 9 пункты белән тапшырылган документлар һәм мәгълүматлар нигезендә Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге бүлеге 10 көн эчендә компенсация билгеләү турында яки аны билгеләүдән баш тарту хакында карар кабул итә һәм гариза бирүчегә кабул ителгән карар турында хәбәр итә дип билгеләнгән. Нигезләмәнең үзара бәйләнештәге 8 һәм 11 пунктлары эчтәлегеннән аңлашылганча, законлы вәкилгә күрсәтелгән дәүләт учреждениесенә гариза һәм тиешле документлар белән бер генә тапкыр мөрәҗәгать итү җитә, шуннан соң аңа компенсация ай саен аны алуга хокукны расларга кирәк булмыйча түләнеп бара, чөнки алдагы ата-ана түләве турында мәгълүматлар муниципаль берәмлекнең дәүләт һәм муниципаль мәгариф учреждениеләрендә ата-ана түләве исәбен алып бару өчен җаваплы органы һәм мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыра торган бүтән мәгариф оешмалары тарафыннан бирелә.

Шул рәвешле үзенең хокукый табигате һәм асылы буенча китерелгән җайга салу компенсация түләү мәсьәләсен хәл итү өчен җаваплы органны, компенсация алу шартларын, компенсацияне билгеләү турында яки аны билгеләүдән баш тарту хакында карар кабул ителү вакытын билгели торган оештыру-процедура механизмы булып тора.

Компенсация алуга дәгъва итүче гражданның һәм Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге бүлегенең Нигезләмәдәге 8 пункт белән күздә тотылган документлар аша үзара бәйләнешенә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү белән бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала торган «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нормаларының гамәли көче кагыла. Мондый нәтиҗә әлеге Федераль законның 1 статьясындагы 2 өлеше һәм 2 статьясындагы 8 пунктының үзара бәйләнештә булган нигезләмәләреннән килеп чыга, алар буенча аның гамәлдә булу көче, аерым алганда, дәүләт һәм муниципаль

хезмәтләр күрсәтүдә катнаша торган оешмаларның эшчәнлегенә кагыла, алар исәбенә дәүләт органы ведомствосындагы оешмалар — тиешенчә Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органы тарафыннан булдырылган дәүләт учреждениеләре һәм унитар предприятиеләр, шулай ук дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтә торган башка оешмалар керә. Бу шулай ук югарыда күрсәтелгән Федераль законның 12 статьясы нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 19 ноябрендәге 639 номерлы боерыгы белән раслана, аның белән компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели торган Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыра торган мәгариф оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламенты расланган.

Дәүләт хезмәтләрен күрсәткәндә гариза бирүче белән бәйләнешкә карата таләпләрне билгеләп, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» гы Федераль закон шуны күздә тота: дәүләт хезмәтләрен күрсәтә торган органнар гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары яисә дәүләт органнары ведомствосындагы дәүләт хезмәтләрен күрсәтүдә катнаша торган оешмалар карамагында булган документлар һәм мәгълүмат бирүне таләп итәргә хокуклы түгел (7 статьяның 1 өлешендәге 2 пункты).

Әлеге таләпне билгеләп, федераль закон чыгаручы шул ук вакытта югарыда күрсәтелгән статьяның 6 өлеше нигезендә ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә таләп ителә алмаган аерым документлар мөнәсәбәтендә чыгарма күздә тоткан. Карала торган эшнең предметына карата андый документлар исәбенә түбәндәгеләр керә: гражданлык хәле актларын дәүләт теркәве турында таныклыклар; белем бирү эшчәнлеген башкара торган оешмалар бирүче уку белән бәйле документлар; гражданның социаль ярдәм алуга хокукын раслый торган документлар.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, тиңдәш характердагы чыгарма гариза бирүчеләрдән дәүләт хезмәтләрен алу өчен кирәкле һәм башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмаларга мөрәҗәгать итү белән бәйле булган гамәлләрне, шул исәптән килештерүләрне башкаруны таләп итүне тыю мөнәсәбәтендә дә куелган. Күрсәтелгән Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты һәм 9 статьясының 1 өлешендәге 2 пунктының үзара бәйле нигезләмәләре буенча андый чыгарма, аерым алганда, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты раслый торган хезмәтләр исемлегенә кертелүче кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр мөнәсәбәтендә беркетелгән.

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар күрсәтә торган хезмәтләр исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 13 августындагы 675 номерлы карары белән расланган. Күрсәтелгән Исемлеккә шул исәптән белем бирү эшчәнлеген башкара торган оешмалар тарафыннан белешмәләр һәм башка документлар бирү буенча хезмәтләр кертелгән.

Димәк, дәгъва белдерелә торган нормада законлы вәкил (ата яки ана, уллыкка (кызлыкка) алучы, опекун) тарафыннан компенсация алу өчен Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге бүлегенә мәҗбүри рәвештә тапшырылырга тиешле документларны, шул исәптән баланы тиешле мәгариф оешмасына урнаштыру турында килешү күчермәсен, белем бирү оешмасында баланы караштырып торган һәм караган өчен түләүгә квитанция күчермәсен билгеләп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты югарыда аталган федераль һәм республика законнары нормаларына таянган һәм законнарда билгеләнгән компенсация түләүгә гарантия алу хокукын тормышка ашыруга комачаулый торган ниндидер өстәмә нигезсез таләпләр куймаган.

3.2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның сүзгә-сүз мәгънәсен дә, хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Шуңа бәйле рәвештә Нигезләмәнең дәгъвалана торган нормасының конституциячеллеген аның хокуктагы кулланылуы күзлегеннән чыгып әлеге мәсьәләгә катнашы булган башка норматив хокукый актлар, аерым алганда, Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыра торган мәгариф оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба — Административ регламент) белән үзара бәйләнештә бәяләргә кирәк.

Административ регламент (гражданка Л.В. Кирюшинаның компенсация билгеләү турында гариза белән мөрәҗәгать итү моментына гамәлдә булган редакциясендә) нормаларына анализ шуны күрсәтә: аның белән, Нигезләмәнең дәгъвалана торган 8 пункты белән чагыштырганда, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына торган документларның тулырак исемлеге билгеләнгән. Шулай, Административ регламентның 2.5 пункты нигезендә көндезге формада белем алучы 18 яшьтән 23 яшькә кадәрге балалары булмаган гариза бирүчегә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гариза гына тапшыру җитәрлек булган. Шул ук вакытта башка документлар, шул исәптән Нигезләмәнең дәгъва белдерелә торган 8 пункты белән каралганнары Административ

регламентның 2.6 пункты нигезендә ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиеш булган һәм гариза бирүченең аларны тапшырмавы әлеге хезмәтне күрсәтүдән баш тартуга нигез була алмаган.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 12 октябрендәге 730 номерлы боерыгы белән Административ регламент яңа редакциядә бәян ителгән. Шулай да Административ регламентның хәзер гамәлдә булган редакциясендә дә әлеге хезмәт күрсәтелсен өчен гариза бирүче тапшырырга тиешле документлар һәм ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә алына торган документлар исемлекләре Нигезләмәнең дәгъва белдерелә торган 8 пунктында каралган документлар исемлеге белән туры килми.

Шул ук вакытта «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы Федераль законның 7 статьясындагы 6.1 өлеше нигезендә Россия Федерациясе субъектлары дәрәҗәсендә документларны ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә алу, турыдан-туры федераль законда каралган очраклардан тыш, бары тик Россия Федерациясе субъекты законы яки Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы норматив хокукый акты белән каралганда гына мөмкин.

Моңа бәйле рәвештә дәгъва белдерелә торган Нигезләмә чикләреннән чыга торган Административ регламент билгеләгән җайга салу «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы Федераль законның китерелгән нормалары белән, шулай ук гомумән хокукый дәүләт һәм закон өстенлеге конституциячел принциплары белән дә, шул исәптән Татарстан Республикасы Конституциясенең 29 статьясы (өченче өлеш) нигезләмәсе белән туры килми, аның буенча конституциячел хокукларны һәм ирекләрне гамәлгә ашыру, саклау һәм яклау тәртибе законнар белән билгеләнә.

Моннан чыгып, Татарстан Республикасы Конституция суды шуны билгеләп үтә: Административ регламент гамәлдәге редакциясендә дә, үз көчен югалткан редакциясендә дә ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация билгеләү яки билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нинди дә булса өстәмә нигезләр билгели алырлык тиешле норматив хокукый акт булып тормый. Әмма әлеге ведомство норматив хокукый акты «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә гражданнар шикаятьләре буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы була алмый.

3.3. Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә һәркем хосусый тормышының кагылгысызлыгына, шәхси һәм гаилә серенә, үзенең намусын һәм абруйлы исемен яклауга хокуклы (36 статья, беренче өлеш).

Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, башка дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан да башкарыла торган шәхси мәгълүматларны

эшкәртү белән бәйле мөнәсәбәтләр «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (2011 елның 25 июлендәге 261-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) белән җайга салына. Әлеге Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлеше нигезендә шәхси мәгълүматлар субъекты үзенең шәхси мәгълүматларын бирү турында карар кабул итә һәм аларны эшкәртүгә ризалыкны иркле рәвештә, үз ихтыяры белән һәм үз мәнфәгатендә бирә; шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык конкрет, мәгълүматлы һәм аңлы булырга тиеш; башкасы федераль законда билгеләнгән булмаса, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык шәхси мәгълүматлар субъекты яки аның вәкиле тарафыннан аны алу фактын расларга мөмкинлек бирә торган теләсә кайсы формада бирелергә мөмкин.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртү шартлары шул ук Федераль законның 6 статьясы белән билгеләнгән. Андый шартларга, аерым алганда, шәхси мәгълүматлар субъектының үзенең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы, шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы Федераль законда каралган дәүләт хезмәтләрен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларның функцияләрен һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең башкарма органнары вәкаләтләрен башкару кирәклеге керә.

Китерелгән норманың сүзгә-сүз эчтәлегеннән аңлашылганча, күрсәтелгән шартлар үзара бәйләнештә тормыйлар һәм аларның һәрберсе шәхси мәгълүматлар эшкәртүнең мөстәкыйль нигезе булып тора. Алай гына да түгел, «Шәхси мәгълүматлар турында»гы Федераль законның 9 статьясындагы 2 өлеше гражданнарга дәүләт хезмәтләрен күрсәтүне аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә турыдан-туры бәйли, чөнки ул, шәхси мәгълүматларны эшкәртү дәүләт хезмәтләрен күрсәтүдә катнаша торган оешмалар фунцияләрен башкару өчен кирәк булган очракта, оператор мәгълүматлар эшкәртүне шәхси мәгълүматлар субъекты аларны эшкәртүгә ризалыгын кире алганда да дәвам итәргә хокуклы дип күздә тота. Башкача әйткәндә, дәүләт хезмәтләрен алу өчен мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүченең аның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы аларны алу өчен мәҗбүри шарт булып тормый. Әлеге шартларда Татарстан Республикасы Конституция суды шундый нәтиҗәгә килә: ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәтен алу өчен мөрәҗәгать итеп һәм шуңа кирәкле документларны теркәп, дәүләт хезмәтләрен алучы фактта әлеге хезмәтне күрсәтү өчен кирәкле булган үзенең шәхси мәгълүматларын тапшыруга һәм эшкәртүгә ризалыгын белдерә.

Димәк, Нигезләмәнең 8 пунктындагы нормалар хокук куллану практикасында мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыра торган мәгариф оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту мөмкинлеген гражданның шундый дәүләт хезмәтен алу өчен бирелә торган гаризасында үзенең шәхси

мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы турында тамга булмаган очракта рөхсәт итә торган итеп кабул ителмәскә тиеш.

Шулай итеп, Нигезләмәнең 8 пункты гамәлдәге хокукый җайга салу системасында, әлеге карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәне исәпкә алып, үзенең характеры һәм гавами-хокукый билгеләнеше буенча дәүләт тарафыннан гражданнарның социаль яклауга хокукларын тормышка ашыру чараларын социаль ярдәм чараларын күрсәткәндә адреслылык принцибы үтәлеп тәэмин итүгә юнәлгән механизмның бер элементы булып тора, үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын юкка чыгара, чикли яки башкача боза торган итеп карала алмый һәм шуның белән Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килми.

Гражданка Л.В. Кирюшинадан компенсация билгеләү турындагы гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булган сәбәпләрнең, шул исәптән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә язма ризалыгы булмау сәбәбенең законлы һәм нигезле булуын тикшерү эшнең факттагы хәлләрен ачыклауны күздә тота, бу исә Татарстан Республикасы Конституция судының компетенциясенә керми, чөнки «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары компетенциясенә кергән барлык очракларда факттагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала.

4. Нигезләмәнең мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган 8 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип тану мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыра торган мәгариф оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация алу өчен мөрәҗәгать итү тәртибен камилләштерүгә комачауламый.

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы Федераль законның 7 статьясындагы 6.1 өлеше нигезендә Россия Федерациясе субъектының закон чыгаручысы яки Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы хәзерге вакытта граждан мөстәкыйль тапшыра торган һәм Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен кирәкле документлар ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алынырга мөмкин булган үзенең хокукый җайга салуын билгеләргә хокуклы.

Граждан тарафыннан мөстәкыйль тапшырылырга тиешле документлар һәм мәгълүматның, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле документларның тулы исемлеген билгеләүдә ярдәм алымны тәэмин итү максатында, шулай ук Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләрен күрсәтү кысаларында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек систе-

масын камилләштерү өчен хокукый һәм техник шартларның булуын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Хөкүмәте федераль законнарның тиешле нигезләмәләренә таянган үзенең дискрецион вәкаләтләре чикләрендә ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә алынырга тиешле документлар исемлеген киңәйтергә хокуклы.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71 һәм 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. «Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыра торган мәгариф оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 21 маендагы 338 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыра торган мәгариф оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация алу буенча мөрәҗәгать итү һәм аны түләү тәртибе турындагы нигезләмәнең 8 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.
2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.
3. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы буенча бу Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 68-П

Татарстан Республикасы Конституция суды

ИМЕНЕМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**по делу о проверке конституционности абзаца четвертого пункта 4 приложения № 1 и абзаца четвертого пункта 4 приложения № 2 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год» в связи с жалобами граждан С.Я. Якуповой и М.Н. Павловой**

7 июля 2016 года город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

руководствуясь статьей 109 (часть четвертая) Конституции Республики Татарстан, частями пятой и девятой статьи 3, частью первой и пунктом 1 части второй статьи 39, статьями 68, 83, 100, 101 и 103 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан»,

рассмотрел в открытом судебном заседании дело о проверке конституционности абзаца четвертого пункта 4 приложения № 1 и абзаца четвертого пункта 4 приложения № 2 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год».

Поводом к рассмотрению дела явились обращения в форме жалобы граждан С.Я. Якуповой и М.Н. Павловой. Основанием к рассмотрению дела явилась обнаружившаяся неопределенность в вопросе о том, соответствуют ли оспариваемые заявителями нормативные положения Конституции Республики Татарстан.

Поскольку обе жалобы касаются одного и того же предмета, Конституционный суд Республики Татарстан, руководствуясь частью второй статьи 50 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», соединил дела по этим жалобам в одном производстве.

Заслушав сообщение судьи-докладчика Л.В. Кузьминой, объяснения сторон — гражданки М.Н. Павловой, представителя органа, издавшего оспариваемый нормативный правовой акт,— заместителя начальника юридического и информационного отдела Комитета жилищно-коммунального хозяйства Исполнительного комитета муниципального образования города Казани Р.Н. Сафина, специалиста, приглашенного в судебное заседание по ходатайству представителя органа, издавшего оспариваемый нормативный правовой акт, — заместителя председателя Комитета жилищно-коммунального хозяйства Исполнительного комитета муниципального образования города Казани Р.Б. Гариповой, выступления приглашенных в судебное заседание: представителя Президента Республики Татарстан — главного советника

отдела по законопроектной работе Государственно-правового управления Президента Республики Татарстан Р.В. Сидакова, представителя Государственного Совета Республики Татарстан — исполняющего обязанности начальника Правового управления Аппарата Государственного Совета Республики Татарстан М.Б. Сунгатуллина, представителя Кабинета Министров Республики Татарстан — Правительства Республики Татарстан — начальника Правового управления Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан А.Б. Гревцова, представителя Председателя Верховного суда Республики Татарстан — судьи Верховного суда Республики Татарстан Э.С. Каминского, представителя Прокурора Республики Татарстан — начальника отдела по надзору за законностью нормативных правовых актов Управления по надзору за исполнением федерального законодательства прокуратуры Республики Татарстан А.Р. Валиахметова, представителя Уполномоченного по правам человека в Республике Татарстан — ведущего консультанта отдела по вопросам восстановления прав граждан аппарата Уполномоченного по правам человека в Республике Татарстан Р.Р. Мингалиева, исследовав представленные документы и иные материалы, Конституционный суд Республики Татарстан

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратились граждане С.Я. Якупова и М.Н. Павлова с жалобами на нарушение их конституционных прав и свобод абзацем четвертым пункта 4 приложения № 1 и абзацем четвертым пункта 4 приложения № 2 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год».

Данным постановлением утвержден и введен в действие размер платы за содержание жилых помещений для нанимателей жилых помещений по договорам социального найма и договорам найма жилых помещений государственного или муниципального жилищного фонда, а также собственников помещений в многоквартирных домах, не принявших решения о выборе способа управления многоквартирным домом и (или) на общем собрании решения об установлении размера платы за содержание жилых помещений, по видам услуг на период с 1 января 2016 года по 30 июня 2016 года (приложение № 1) и с 1 июля 2016 года по 31 декабря 2016 года (приложение № 2).

Оспариваемыми положениями установлено, что тариф за техническое обслуживание и ремонт строительных конструкций, инженерных систем зданий и иного общедомового имущества, в том числе систем коллективного приема телевидения, составляет 0,57 руб. с 1 кв. метра общей площади жилого помещения в месяц.

Как следует из содержания жалоб и приложенных к ним ко-

пий документов, гражданка С.Я. Якупова является собственником, а гражданка М.Н. Павлова — нанимателем жилого помещения в многоквартирных домах города Казани, в которых решение об установлении размера платы за содержание жилых помещений на общем собрании не принято, и в силу этого размер указанной платы в таких домах устанавливается в соответствии с тарифом, определяемым Исполнительным комитетом муниципального образования города Казани.

Заявительницы указывают, что не пользуются коллективной антенной, однако вынуждены оплачивать ее техническое обслуживание и ремонт. По их мнению, целью технического обслуживания и ремонта является предоставление услуг телевизионного вещания и, следовательно, плата должна взиматься именно за эти услуги, однако обжалуемые положения не связывают указанную плату с пользованием антенной и не предусматривают различия в тарифе для тех, кто пользуется антенной, и тех, кто ею не пользуется. Гражданка М.Н. Павлова также отмечает, что коллективная антенна не должна входить в общее имущество в многоквартирном доме.

На основании изложенного граждане С.Я. Якупова и М.Н. Павлова просят Конституционный суд Республики Татарстан признать абзац четвертый пункта 4 приложения № 1 и абзац четвертый пункта 4 приложения № 2 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год» не соответствующими статьям 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 49 и 51 Конституции Республики Татарстан, согласно которым все равны перед законом и судом; государство гарантирует равенство прав и свобод человека и гражданина независимо от социального и имущественного положения и иных обстоятельств; любые формы ограничения прав и свобод либо установление преимуществ граждан по расовым, национальным и другим признакам запрещаются; право частной собственности охраняется законом; Республика Татарстан защищает интересы потребителя и поддерживает общественную деятельность по защите его прав, потребители имеют право на возмещение ущерба, причиненного производителями товаров, услуг, в установленном законом порядке.

1.1. Оспариваемое постановление, устанавливая размер платы за содержание жилых помещений для нанимателей жилых помещений по договорам социального найма и договорам найма жилых помещений государственного или муниципального жилищного фонда, а также собственников помещений в многоквартирных домах, не принявших решения о выборе способа управления многоквартирным домом и (или) на общем собрании решения об установлении размера платы за содержание жилых помещений, по видам услуг, предусматривает изменение отдельных тарифов в течение календарного года, в связи с чем размеры указанной платы, установленные в приложении № 1, действуют

с 1 января по 30 июня 2016 года, а в приложении № 2 — с 1 июля по 31 декабря 2016 года. Несмотря на то, что в обоих приложениях нормы об установлении тарифа за техническое обслуживание и ремонт систем коллективного приема телевидения абсолютно идентичны, исследованные Конституционным судом Республики Татарстан материалы свидетельствуют о том, что в деле гражданок С.Я. Якуповой и М.Н. Павловой фактически был применен только абзац четвертый пункта 4 приложения № 1. В связи с этим в силу пункта 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с положениями статьи 63, а также статьи 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» производство по жалобам заявительниц в отношении абзаца четвертого пункта 4 приложения № 2 подлежит прекращению.

1.2. В соответствии с частью третьей статьи 68 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционный суд Республики Татарстан принимает постановления только по предмету, указанному в обращении, и лишь в отношении той части акта, конституционность которой подвергается сомнению в обращении. Конституционный суд Республики Татарстан при принятии решения не связан основаниями и доводами, изложенными в обращении.

Таким образом, предметом рассмотрения Конституционного суда Республики Татарстан по настоящему делу является абзац четвертый пункта 4 приложения № 1 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год», устанавливающий тариф за техническое обслуживание и ремонт строительных конструкций, инженерных систем зданий и иного общедомового имущества, в том числе систем коллективного приема телевидения.

2. Оспариваемые правовые положения затрагивают вопросы жилищного законодательства, которое согласно статье 72 (часть 1, пункт «к») Конституции Российской Федерации находится в совместном ведении Российской Федерации и ее субъектов. В силу статьи 76 (части 2 и 5) Конституции Российской Федерации законы и иные нормативные правовые акты субъектов Российской Федерации в данной сфере принимаются в соответствии с федеральными законами и не могут им противоречить.

Согласно части третьей статьи 156 Жилищного кодекса Российской Федерации органам местного самоуправления предоставлено полномочие по установлению размера платы за пользование жилым помещением (платы за наем), платы за содержание и ремонт жилого помещения для нанимателей жилых помещений по договорам социального найма и договорам найма жилых помещений государственного или муниципального жилищного фонда и размера платы за содержание жилого помещения для собственников жилых помещений, которые не приняли решение о выборе способа управления многоквартирным домом. Частью

четвертой статьи 158 указанного Кодекса также предусмотрено, что в случае, если собственники помещений в многоквартирном доме на их общем собрании не приняли решение об установлении размера платы за содержание жилого помещения, такой размер устанавливается органом местного самоуправления.

Пунктом 6 части первой статьи 16 Федерального закона от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации» к компетенции органов местного самоуправления отнесено в том числе осуществление полномочий органов местного самоуправления в соответствии с жилищным законодательством. Аналогичные по содержанию нормы закреплены пунктом 6 части первой статьи 17 Закона Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан» и пунктом 6 части первой статьи 8 Устава муниципального образования города Казани, утвержденного решением представительного органа муниципального образования города Казани от 17 декабря 2005 года № 3-5.

Согласно части первой статьи 25 Закона Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан», части первой статьи 38 во взаимосвязи с пунктом 17 части третьей статьи 40 Устава муниципального образования города Казани Исполнительный комитет муниципального образования города Казани является исполнительно-распорядительным органом местного самоуправления города Казани, наделенным полномочиями по решению вопросов местного значения, в том числе вопросов, отнесенных к полномочиям органов местного самоуправления в области жилищных отношений Конституцией Российской Федерации, Жилищным кодексом Российской Федерации, другими федеральными законами, а также законами Республики Татарстан.

Таким образом, принимая постановление от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год», Исполнительный комитет муниципального образования города Казани правомерно реализовал полномочие, принадлежащее ему в силу федерального и республиканского законодательства и основанное на взаимосвязанных положениях статей 116 (часть первая) и 118 (часть первая) Конституции Республики Татарстан, согласно которым органы местного самоуправления обеспечивают самостоятельное в соответствии с законом и под свою ответственность решение населением вопросов местного значения.

3. Провозглашая Республику Татарстан правовым государством, Конституция Республики Татарстан возлагает на Республику Татарстан обязанность признавать, соблюдать и защищать права и свободы человека и гражданина как высшую ценность (часть первая статьи 1 и статья 2). При этом Конституция Республики Татарстан закрепляет, что граждане Российской Федерации обладают на территории Республики Татарстан всеми

правами и свободами и несут равные обязанности в соответствии с Конституцией Республики Татарстан, общепризнанными принципами и нормами международного права (статья 22). Республика Татарстан защищает интересы потребителя и поддерживает общественную деятельность по защите его прав (статья 51). Указанные конституционные положения реализуются также в жилищной сфере Республики Татарстан и определяют содержание и смысл нормативных правовых актов в том числе органов местного самоуправления, принимаемых по вопросам регулирования тарифов на жилищно-коммунальные услуги.

Порядок определения размера платы за содержание и ремонт жилого помещения, обеспечивающий, в частности, содержание общего имущества в многоквартирном доме, установлен нормами Жилищного кодекса Российской Федерации, в том числе его статьями 155, 156 и 158. Оспариваемый заявительницами нормативный правовой акт принят в рамках реализации названных норм федерального законодательства и, как это следует из его пункта 8, предусматривает, что собственники помещений в многоквартирном доме несут расходы на содержание принадлежащих им помещений, а также участвуют в расходах на содержание общего имущества в многоквартирном доме соразмерно своей доле в праве общей долевой собственности на это имущество.

Такой подход корреспондирует правовой позиции Конституционного Суда Российской Федерации, согласно которой установление для собственников помещений в многоквартирном доме обязательного участия в расходах по содержанию и ремонту общего имущества такого дома пропорционально размеру принадлежащих им долей в праве общей собственности на общее имущество в доме соответствует общеправовому принципу несения собственником бремени содержания своего имущества, направлено на поддержание дома в состоянии, отвечающем — в общих интересах собственников помещений в многоквартирном жилом доме — санитарным и техническим требованиям (определения от 22 апреля 2014 года № 947-О и от 20 ноября 2014 года № 2667-О).

Правовые условия содержания общего имущества согласно части третьей статьи 39 Жилищного кодекса Российской Федерации установлены Правилами содержания общего имущества в многоквартирном доме, утвержденными постановлением Правительства Российской Федерации от 13 августа 2006 года № 491 (далее — Правила), в соответствии с которыми собственники помещений вправе самостоятельно совершать действия по содержанию и ремонту общего имущества или привлекать иных лиц для оказания услуг и выполнения работ по содержанию и ремонту общего имущества с учетом выбранного способа управления многоквартирным домом (пункт 12), а также обязаны утвердить на общем собрании перечень услуг и работ, условия их оказания и выполнения, а также размер их финансирования (пункт 17).

В случае если собственники помещений не приняли решение о выборе способа управления многоквартирным домом либо на общем собрании выбрали способ непосредственного управления

многоквартирным домом, но не приняли решение об установлении размера платы за содержание и ремонт жилого помещения (как произошло в многоквартирном доме, в котором проживает гражданка С.Я. Якупова), то в соответствии с частью третьей статьи 156 и частью четвертой статьи 158 Жилищного кодекса Российской Федерации, а также пунктами 34 и 36 Правил размер платы за содержание и ремонт жилого помещения устанавливается органами местного самоуправления.

Размер платы за содержание и ремонт жилого помещения устанавливается органами местного самоуправления и для нанимателей жилых помещений по договорам социального найма и договорам найма жилых помещений государственного и муниципального жилищного фонда в многоквартирном доме, которые (в том числе и гражданка М.Н. Павлова) наряду с собственниками жилых помещений должны нести бремя содержания и ремонта общего имущества такого дома. Причем в случае, если размер вносимой нанимателем жилого помещения платы меньше, чем размер платы, установленный договором управления для собственников помещений, оставшаяся часть платы согласно части четвертой статьи 155 Жилищного кодекса Российской Федерации вносится наймодателем этого жилого помещения в согласованном с управляющей организацией порядке.

Конституционный Суд Российской Федерации в своей практике неоднократно указывал, что наделение органов местного самоуправления в соответствии с частью четвертой статьи 158 Жилищного кодекса Российской Федерации полномочием по установлению размера платы за содержание и ремонт жилого помещения в многоквартирном доме не препятствует осуществлению собственниками помещений в многоквартирном доме права по самостоятельному установлению данной платы, так как реализация указанного полномочия органов местного самоуправления обусловлена отсутствием соответствующего волеизъявления собственников помещений в многоквартирном доме. Указанное законоположение направлено на обеспечение надлежащего функционирования жилищно-коммунального хозяйства, что соответствует интересам как собственников помещений в многоквартирном доме, так и иных участников жилищных правоотношений (определения от 22 марта 2011 года № 357-О-О и от 25 февраля 2016 года № 325-О).

Тем самым применение оспариваемого постановления возможно лишь при условии, что собственники помещений в многоквартирном доме по тем или иным причинам — как зависящим, так и не зависящим от их воли — не совершили предписанных законом действий, направленных на исполнение возложенного на них бремени по содержанию общего имущества в многоквартирном доме, а именно на общем собрании не выбрали способ непосредственного управления многоквартирным домом и (или) не приняли решение об установлении размера платы за содержание и ремонт жилого помещения.

Следовательно, принятие Исполнительным комитетом муни-

ципального образования города Казани оспариваемого постановления в отношении нанимателей жилых помещений по договорам социального найма и договорам найма жилых помещений государственного или муниципального жилищного фонда, а также собственников помещений в многоквартирных домах, не принявших решения о выборе способа управления многоквартирным домом и (или) на общем собрании решения об установлении размера платы за содержание жилых помещений, представляет собой необходимую меру, направленную на обеспечение безопасной эксплуатации многоквартирных домов, и соответствует принципу жилищного законодательства о равенстве обязанностей собственников и нанимателей помещений по содержанию общего имущества многоквартирного дома, установленному статьями 39, 154 и 158 Жилищного кодекса Российской Федерации, и согласуется с принципом равенства, установленным статьей 28 Конституции Республики Татарстан.

При таких обстоятельствах утверждение тарифа за техническое обслуживание и ремонт строительных конструкций, инженерных систем зданий и иного общедомового имущества, в том числе систем коллективного приема телевидения, само по себе не может рассматриваться как нарушающее права и свободы человека и гражданина, поскольку не ограничивает права собственников на принятие решения о выборе способа управления многоквартирным домом и (или) на общем собрании решения об установлении размера платы за содержание общего имущества. По своей правовой природе, буквальному содержанию и целевому назначению обжалуемое постановление Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год» призвано содействовать собственникам жилых помещений в многоквартирных домах в принятии ими решения о выборе способа управления многоквартирным домом и (или) на общем собрании решения об установлении размера платы за содержание жилых помещений. Это подтверждается также положениями пункта 6 оспариваемого постановления, из содержания которых следует, что администрации районов Исполнительного комитета города Казани и Комитет жилищно-коммунального хозяйства Исполнительного комитета города Казани оказывают собственникам жилых помещений методическую и консультационную помощь при проведении ими собраний по вопросу определения перечня услуг и размера платы за содержание жилых помещений в многоквартирном доме.

Применительно к вопросу о том, входит ли коллективная антенна в общее имущество в многоквартирном доме, Конституционный суд Республики Татарстан отмечает следующее. Согласно взаимосвязанным положениям пунктов 1 и 3 части первой статьи 36 Жилищного кодекса Российской Федерации и подпункта «д» пункта 2 Правил в состав общего имущества в многоквартирном доме входит в том числе механическое, электрическое, сани-

тарно-техническое и иное оборудование, находящееся в данном доме за пределами или внутри помещений и обслуживающее более одного помещения. По смыслу приведенных правовых норм система коллективного приема телевидения по своим функциональным характеристикам отвечает признакам общего имущества, поскольку является оборудованием, обслуживающим более одного помещения в многоквартирном доме. При этом в случае если коллективная антенна была предусмотрена в проектной документации многоквартирного дома в составе общего имущества и ее стоимость была включена в стоимость строительства, то услуги по ее техническому обслуживанию входят в состав работ и услуг по содержанию и ремонту общего имущества, а расходы на содержание распределяются независимо от его непосредственного использования между всеми собственниками и нанимателями помещений в многоквартирном доме, основываясь на общеправовом принципе несения бремени содержания имущества, направленном на обеспечение баланса прав и законных интересов всех участников жилищно-правовых отношений.

Вместе с тем обжалуемое правовое регулирование не препятствует собственникам жилых помещений реализовать конкретные правомочия по определению состава общего имущества и соответственно по установлению размера платы за его содержание, а также по уменьшению состава такого имущества путем исключения из него отдельных видов имущества, в том числе систем коллективного приема телевидения, с прекращением платы за их техническое обслуживание и ремонт, поскольку в силу пункта 1 Правил собственники помещений вправе самостоятельно определить состав общего имущества.

Однако исследование вопроса о правомерности включения системы коллективного приема телевидения в состав общего имущества многоквартирных домов, в которых проживают заявительницы, равно как и оценка обоснованности расчета размера тарифа за техническое обслуживание и ремонт систем коллективного приема телевидения, предполагает установление фактических обстоятельств и не входит в компетенцию Конституционного суда Республики Татарстан, поскольку в силу части девятой статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционный суд Республики Татарстан решает исключительно вопросы права и при осуществлении конституционного судопроизводства воздерживается от установления и исследования фактических обстоятельств во всех случаях, когда это входит в компетенцию других судов или иных органов государственной власти Республики Татарстан.

Таким образом, абзац четвертый пункта 4 приложения № 1 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год», устанавливающий тариф за техническое обслуживание и ремонт строительных конструкций, инженерных систем

зданий и иного общедомового имущества, в том числе систем коллективного приема телевидения, является одним из элементов правового механизма поддержания надлежащего состояния имущества в многоквартирном доме и не может рассматриваться как отменяющий, ограничивающий или иным образом нарушающий конституционные права и свободы человека и гражданина и тем самым не противоречит статьям 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 49 и 51 Конституции Республики Татарстан.

На основании изложенного, руководствуясь статьями 6, 63, частями первой и второй статьи 66, статьями 67, 68, 69, 71, 73 и пунктом 1 части первой статьи 104 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**постановил:**

1. Признать абзац четвертый пункта 4 приложения № 1 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год» соответствующим Конституции Республики Татарстан.

2. Прекратить производство по настоящему делу в части, касающейся проверки конституционности абзаца четвертого пункта 4 приложения № 2 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год», поскольку обращения заявительниц в данной части не являются допустимыми.

3. Настоящее Постановление окончательно, не подлежит обжалованию, вступает в силу немедленно после его провозглашения, действует непосредственно и не требует подтверждения другими органами и должностными лицами.

4. Согласно статье 72 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» настоящее Постановление подлежит незамедлительному опубликованию в газетах «Ватаным Татарстан» и «Республика Татарстан». Постановление должно быть опубликовано также в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 69-П

Конституционный суд
Республики Татарстан

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИСЕМЕ БЕЛӘН

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

**гражданнар С.Я. Якупова һәм М.Н. Павлова шикаятьләренә бәйле рәвештә «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымтаның 4 пунктындагы дүртенче абзацының һәм 2 нче кушымтаның 4 пунктындагы дүртенче абзацының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

2016 ел
7 июль
Казан шәһәре

# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымтаның 4 пунктындагы дүртенче абзацының һәм 2 нче кушымтаның 4 пунктындагы дүртенче абзацының конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданнар С.Я. Якупова һәм М.Н. Павлованың шикаять формасындагы мөрәҗәгатьләре сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүкилмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Ике шикаять тә бер үк предметка кагылышлы булганга күрә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 50 статьясындагы икенче өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге шикаятьләр буенча эшләрне бер башкаруга берләштерде.

Докладчы судья Л.В. Кузьмина мәгълүматын, яклар — гражданка М.Н. Павлова, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты юридик һәм мәгълүмат бүлеге башлыгы урынбасары Р.Н. Сафин, суд утырышына дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле үтенечнамәсе буенча чакырылган белгеч — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты рәисе урынбасары Р.Б. Гарипова аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татар-

стан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең закон проектлары эшләү бүлеге баш киңәшчесе Р.В. Сидаковның, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы М.Б. Сөнгатуллинның, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы А.Б. Гревцовның, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы Э.С. Каминскийның, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы прокуратурасы Федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге башлыгы А.Р. Вәлиәхмәтовның, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппараты гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлегенең әйдәүче консультанты Р.Р. Мингалиевның чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданнар С.Я. Якупова һәм М.Н. Павлова «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымтаның 4 пунктындагы дүртенче абзацы һәм 2 нче кушымтаның 4 пунктындагы дүртенче абзацы белән үзләренең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаятьләр белән мөрәҗәгать иттеләр.

Әлеге карар белән социаль наем килешүе һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак биналарга наем килешүе буенча торак биналарны яллаучылар, шулай ук күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак биналарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күп фатирлы йортлардагы биналар хуҗалары өчен торак биналарны карап тотуга түләү күләме хезмәт күрсәтү төрләре буенча 2016 елның 1 гыйнварыннан алып 2016 елның 30 июненә кадәр (1 нче кушымта) һәм 2016 елның 1 июленнән алып 2016 елның 31 декабренә кадәр (2 нче кушымта) расланган һәм гамәлгә кертелгән.

Дәгъвалана торган нигезләмәләр белән төзелеш конструкцияләренә, биналарның инженерлык системаларына һәм йорттагы башка уртак милеккә, шул исәптән телевидениене күмәк кабул итү системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау өчен тариф айга торак бинаның гомуми мәйданының 1 кв. метрыннан 0,57 сум тәшкил итә, дип билгеләнгән.

Шикаятьләр эчтәлегеннән һәм аларга кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка С.Я. Якупова Казан шәһәренең гомуми җыелышта торак биналарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул ителмәгән күп фатирлы йортларындагы торак бина хуҗасы, ә гражданка М.Н. Павлова — яллаучысы булып тора, шуңа бәйле рәвештә андый йортларда күрсәтелгән түләү күләме Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан куела торган тариф нигезендә билгеләнә.

Мөрәҗәгать итүчеләр күрсәткәнчә, алар күмәк антеннадан файдаланмыйлар, ләкин аңа техник хезмәт күрсәтү һәм аны ремонтлау өчен түләргә мәҗбүр. Алар фикеренчә, техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлауның максаты булып телевидение хезмәтләрен күрсәтү тора һәм, димәк, түләү нәкъ менә шул хезмәтләр өчен алынырга тиеш, әмма дәгъва белдерелә торган нигезләмәләр күрсәтелгән түләүне антеннаны куллануга бәйләмиләр һәм антеннаны кулланучылар һәм аны кулланмаучылар өчен тарифта аермалык булуны күздә тотмыйлар. Гражданка М.Н. Павлова шулай ук күмәк антенна күп фатирлы йорттагы уртак милеккә кертелмәскә тиеш дип билгеләп үтә.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар С.Я. Якупова һәм М.Н. Павлова Татарстан Республикасы Конституция судыннан «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымтаның 4 пунктындагы дүртенче абзацын һәм 2 нче кушымтаның 4 пунктындагы дүртенче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 49 һәм 51 статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген социаль һәм мөлкәти хәленә һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең теләсә кайсы рәвеше йә аларга өстенлекләр билгеләү тыела; хосусый милек хокукы закон белән саклана; Татарстан Республикасы кулланучы мәнфәгатьләрен яклый һәм аның хокукларын яклау буенча иҗтимагый эшчәнлекне хуплый, кулланучылар товар җитештерүчеләрнең, хезмәт күрсәтүчеләрнең китергән зыянын законда билгеләнгән тәртиптә түләттерергә хокуклы.

1.1. Дәгъвалана торган карар социаль наем килешүе һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак биналарга наем килешүе буенча торак биналарны яллаучылар, шулай ук күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак биналарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күп фатирлы йортлардагы биналар хуҗалары өчен торак биналарны карап тотуга түләү күләмен хезмәт күрсәтү төрләре буенча билгеләп, ае-

рым тарифларның календарь ел дәвамында үзгәрүен күздә тота, шуңа бәйле рәвештә күрсәтелгән түләүнең 1 нче кушымтада билгеләнгән күләме 2016 елның 1 гыйнварыннан 30 июненә кадәр, ә 2 нче кушымтада — 2016 елның 1 июленнән 31 декабренә кадәр гамәлдә. Ике кушымтада да телевидениене күмәк кабул итү системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау өчен тариф билгеләү турындагы нормалар тулысынча тәңгәл килүгә карамастан, Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан тикшерелгән материаллар гражданнар С.Я. Якупова һәм М.Н. Павлова эшләрендә фактта 1 нче кушымтаның 4 пунктындагы дүртенче абзацы гына кулланылганын күрсәтә. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 63 статьясы, шулай ук 101 статьясы нигезләмәләре буенча 2 нче кушымтаның 4 пунктындагы дүртенче абзацы мөнәсәбәтендә мөрәҗәгать итүчеләрнең шикаятьләре буенча эш башкару туктатылырга тиеш.

1.2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы өченче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән орган актының конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карарлар кабул итә. Карар кабул иткәндә Татарстан Республикасы Конституция суды мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, төзелеш конструкцияләренә, биналарның инженерлык системаларына һәм йорттагы башка уртак милеккә, шул исәптән телевидениене күмәк кабул итү системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау өчен тариф билгели торган «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымтаның 4 пунктындагы дүртенче абзацы әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора.

2. Дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләр торак законнары мәсьәләләренә кагыла, алар Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлеш, «к» пункты) нигезендә Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы (2 һәм 5 өлешләр) буенча Россия Федерациясе субъектларының әлеге өлкәдәге законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнар нигезендә кабул ителә һәм аларга каршы килә алмый.

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясындагы 3 өлеше буенча җирле үзидарә органнарына социаль наем килешүе һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак биналарга наем килешүе буенча торак биналарны яллаучылар өчен торак бинадан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү), торак бинаны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен һәм күп

фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак биналар хуҗалары өчен торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча вәкаләт бирелгән. Күрсәтелгән Кодексның 158 статьясындагы дүртенче өлеше белән күздә тотылганча, күп фатирлы йорттагы биналар хуҗалары үзләренең гомуми җыелышында торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән булсалар, мондый күләм җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы беренче өлешенең 6 пункты белән җирле үзидарә органнары компетенциясенә шул исәптән торак законнары нигезендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кертелгән. Эчтәлеге буенча тиңдәш нормалар «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясындагы беренче өлешенең 6 пункты һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 8 статьясындагы беренче өлешенең 6 пункты белән беркетелгән.

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясындагы беренче өлеше, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 38 статьясындагы беренче өлеше белән үзара бәйләнештә 40 статьясының өченче өлешендәге 17 пункты буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне, шул исәптән җирле үзидарә органнарының торак мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтләренә Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Торак кодексы, башка федераль законнар, шулай ук Татарстан Республикасы законнары белән кертелгән мәсьәләләрне хәл итү йөкләнгән Казан шәһәре җирле үзидарәсенең башкарма-күрсәтмә органы булып тора.

Шулай итеп, «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы карарны кабул итеп, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты федераль һәм республика законнары нигезендә үзенә бирелгән вәкаләтен законлы рәвештә гамәлгә ашырган, әлеге вәкаләт Татарстан Республикасы Конституциясенең үзара бәйләнештәге 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьяларына нигезләнгән, алар буенча җирле үзидарә органнары, закон нигезендә һәм үзенә җаваплылык алып, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне халыкның мөстәкыйль хәл итүен тәэмин итәләр.

3. Татарстан Республикасын хокукый дәүләт буларак игълан итеп, Татарстан Республикасы Конституциясе Татарстан Республикасына кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен иң зур хәзинә буларак тану, үтәү һәм яклау бурычын йөкли (1

статьяның беренче өлеше һәм 2 статья). Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституциясе Россия Федерациясе гражданнары Татарстан Республикасы территориясендә Татарстан Республикасы Конституциясе, халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары нигезендә барлык хокукларга һәм ирекләргә ия һәм бертигез бурычлы, дип беркетә (22 статья). Татарстан Республикасы кулланучы мәнфәгатьләрен яклый һәм аның хокукларын яклау буенча иҗтимагый эшчәнлекне хуплый (51 статья). Күрсәтелгән конституциячел нигезләмәләр шулай ук Татарстан Республикасының торак өлкәсендә гамәлгә ашырыла һәм торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны җайга салу мәсьәләләре буенча кабул ителә торган шул исәптән җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары эчтәлеген һәм мәгънәсен билгелиләр.

Аерым алганда, күп фатирлы йорттагы уртак милекне карап тотуны тәэмин итә торган торак бинаны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү тәртибе Россия Федерациясе Торак кодексы нормалары, шул исәптән аның 155, 156 һәм 158 статьялары белән билгеләнгән. Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив хокукый акт федераль законнарның аталган нормаларын гамәлгә ашыру кысаларында кабул ителгән һәм, аның 8 пунктыннан аңлашылганча, күп фатирлы йорттагы биналар хуҗаларының үзләре хуҗа булган әлеге биналарны карап тотуга чыгымнарны үзләре каплавын, шулай ук, уртак өлешле милек хокукында булган үз өлешеннән чыгып, күп фатирлы йорттагы уртак милекне карап тотуга киткән чыгымнарда катнашуын күздә тота.

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә тәңгәл килеп тора, аның нигезендә күп фатирлы йорттагы биналар хуҗаларына йорттагы уртак милеккә уртак милек хокукында булган үз өлешләренә пропорциональ рәвештә андый йорттагы уртак милекне карап тоту һәм ремонтлауга киткән чыгымнарда мәҗбүри катнашуны билгеләү милекченең үз милкен карап тоту бурычын үтәү тиешлеге гомумхокук принцибына туры килә, йортны күп фатирлы торак йорттагы биналар хуҗаларының уртак мәнфәгатьләрендә санитар һәм техник таләпләргә җавап бирә торган халәттә тотуга юнәлгән (2014 елның 22 апрелендәге 947-О номерлы һәм 2014 елның 20 ноябрендәге 2667-О номерлы билгеләмәләр).

Уртак милекне карап тотуның хокукый шартлары Россия Федерациясе Торак кодексының 39 статьясындагы өченче өлеше буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән расланган Күп фатирлы йортта уртак милекне карап тоту кагыйдәләре (алга таба — Кагыйдәләр) белән билгеләнгән, алар нигезендә биналар хуҗалары уртак милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча гамәлләрне мөстәкыйль башкарырга яки күп фатирлы йорт белән идарә итүнең сайланган ысулын исәпкә алып, уртак милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару өчен башка затларны җәлеп итәргә хокуклы (12 пункт), шулай ук гомуми җыелышта

хезмәтләр һәм эшләр исемлеген, аларны күрсәтү һәм башкару шартларын, аларны финанслау күләмен расларга тиешләр (17 пункт).

Биналар хуҗалары күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән булсалар яки гомуми җыелышта күп фатирлы йорт белән турыдан-туры идарә итү ысулын сайлап, торак бинаны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү хакында карар кабул итмәгән булсалар (гражданка С.Я. Якупова яшәгән күп фатирлы йортта килеп чыккан кебек), Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясындагы өченче өлеше һәм 158 статьясындагы дүртенче өлеше, шулай ук Кагыйдәләрнең 34 һәм 36 пунктлары нигезендә торак бинаны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

Торак бинаны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме җирле үзидарә органнары тарафыннан социаль наем килешүе һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак биналарга наем килешүе буенча күп фатирлы йорттагы торак биналарны яллаучыларга да билгеләнә, алар (шул исәптән гражданка М.Н. Павлова) торак биналар хуҗалары белән беррәттән андый йортның уртак милеген карап тоту һәм ремонтлау бурычын үтәргә тиешләр. Шул ук вакытта торак бинаны яллаучы тарафыннан кертелә торган түләү идарә итү килешүе белән биналар хуҗалары өчен билгеләнгән түләү күләменнән кимрәк булса, түләүнең калган өлеше Россия Федерациясе Торак кодексының 155 статьясындагы дүртенче өлеше нигезендә идарә итүче оешма белән килешенгән тәртиптә шушы торак бинаны яллауга бирүче тарафыннан кертелә.

Россия Федерациясе Конституция Суды үз практикасында берничә тапкыр күрсәткәнчә, Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы дүртенче өлеше нигезендә җирле үзидарә органнарына күп фатирлы йорттагы торак бинаны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү буенча вәкаләт бирү күп фатирлы йорттагы биналар хуҗалары тарафыннан әлеге түләүне мөстәкыйль билгеләү хокукын тормышка ашыруга комачауламый, чөнки җирле үзидарә органнарының күрсәтелгән вәкаләтен гамәлгә ашыру күп фатирлы йорттагы биналар хуҗаларының тиешле ихтыяр белдерүләренең булмавы белән аңлатыла. Күрсәтелгән закон нигезләмәсе торак-коммуналь хуҗалыгының тиешле рәвештә эшләп торуын тәэмин итүгә юнәлгән, бу исә күп фатирлы йорттагы биналар хуҗаларының да, торакка кагылышлы хокук мөнәсәбәтләрендә башка торучыларның да мәнфәгатьләренә туры килә (2011 елның 22 мартындагы 357-О-О номерлы һәм 2016 елның 25 февралендәге 325-О номерлы билгеләмәләр).

Шул рәвешле дәгъва белдерелә торган карар түбәндәге шарт белән генә кулланылырга мөмкин: күп фатирлы йорттагы биналар хуҗалары аларның ихтыярына бәйле булган һәм бәйле булмаган теге яки бу сәбәпләр буенча үзләренә йөкләнгән күп фатирлы йорттагы уртак милекне карап тоту бурычын үтәргә юнәлгән

закон белән билгеләнгән гамәлләрне башкармаганнар, атап әйткәндә, гомуми җыелышта күп фатирлы йорт белән турыдан-туры идарә итү ысулын сайламаганнар һәм (яки) торак бинаны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгәннәр.

Димәк, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының дәгъва белдерелә торган карарны социаль наем килешүе һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак биналарга наем килешүе буенча торак биналарны яллаучылар, шулай ук күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак биналарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күп фатирлы йортлардагы биналар хуҗалары мөнәсәбәтендә кабул итүе күп фатирлы йортлардан хәвефсез файдалануны тәэмин итүгә юнәлгән кирәкле чара булып тора һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 39, 154 һәм 158 статьялары белән билгеләнгән күп фатирлы йорттагы уртак милекне карап тоту буенча биналар хуҗалары һәм яллаучылары бурычларының тигезлеге торак законнары принцибына туры килә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 статьясында билгеләнгән тигезлек принцибына тәңгәл килә.

Мондый шартларда төзелеш конструкцияләренә, биналарның инженерлык системаларына һәм йорттагы башка уртак милеккә, шул исәптән телевидениене күмәк кабул итү системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау өчен тарифны раслау үзеннән-үзе кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен боза торган итеп карала алмый, чөнки милекчеләрнең күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта уртак милекне карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итүгә хокукларын чикләми. Үзенең хокукый табигате, сүзгә-сүз эчтәлеге һәм максатчан билгеләнеше буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы дәгъвалана торган карары күп фатирлы йортлардагы торак биналар хуҗаларына аларның күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак биналарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итүләрендә булышлык күрсәтергә тиеш. Бу шулай ук дәгъва белдерелә торган карарның 6 пунктындагы нигезләмәләр белән дә раслана, аларның эчтәлегеннән аңлашылганча, Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты, торак биналарның хуҗалары күрсәтелүче хезмәтләр исемлеген һәм күп фатирлы йортта торак биналарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү мәсьәләсе буенча җыелышлар үткәргән вакытта, аларга методик һәм консультация ярдәме күрсәтә.

Күмәк антеннаның күп фатирлы йорттагы уртак милеккә

керү-кермәве мәсьәләсенә килгәндә, Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләрне билгеләп үтә. Россия Федерациясе Торак кодексының 36 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 3 пунктлары белән Кагыйдәләрнең 2 пунктындагы «д» пунктчасының үзара бәйләнештәге нигезләмәләре буенча күп фатирлы йорттагы уртак милек составына шул исәптән әлеге йортта биналарның эчендә яисә тышында урнашкан һәм бердән күбрәк бинага хезмәт күрсәтә торган механик, электр, санитар-техник һәм башка җайланмалар керә. Китерелгән хокукый нормаларның мәгънәсеннән күренгәнчә, телевидениене күмәк кабул итү системасы үзенең функциональ сыйфатламалары буенча уртак милек билгеләренә җавап бирә, чөнки күп фатирлы йортта бердән күбрәк бинага хезмәт күрсәтә торган җыйланма булып тора. Шул ук вакытта күмәк антенна күп фатирлы йортның проект документларында уртак милек исәбендә каралып, аның бәясе төзелеш бәясенә кертелгән булса, аңа техник хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр уртак милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча эшләр һәм хезмәтләр исәбенә керә, ә карап тоту өчен чыгымнар, торак-хокук мөнәсәбәтләрендә торучыларның барысының да хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре балансын тәэмин итүгә юнәлгән милекне карап тоту бурычын үтәү тиешлеге гомумхокук принцибына таянып, уртак милекне турыдан-туры куллану-кулланмауга карамастан, күп фатирлы йорттагы барлык бина хуҗалары һәм яллаучылары арасында бүленә.

Шул ук вакытта дәгъвалана торган хокукый җайга салу торак биналар хуҗаларына уртак милек составын һәм аны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча, шулай ук андый милек составын аерым милек төрләрен, шул исәптән телевидениене күмәк кабул итү системаларын, аларга техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау өчен түләүне туктатып, аннан чыгару юлы белән кимету буенча конкрет хокукларны гамәлгә ашырырга комачауламый, чөнки Кагыйдәләрнең 1 пункты нигезендә биналар хуҗалары уртак милек составын мөстәкыйль билгеләргә хокуклы.

Ләкин мөрәҗәгать итүчеләр яшәгән күп фатирлы йортлардагы уртак милек исәбенә телевидениене күмәк кабул итү системасын кертүнең законлы булу-булмавы мәсьәләсен тикшерү, телевидениене күмәк кабул итү системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау өчен хисапланган тариф күләменең нигезле булу-булмавын бәяләү кебек үк, фактлагы хәлләрне ачыклауны күздә тота һәм Татарстан Республикасы Конституция суды компетенциясенә керми, чөнки «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары компетенциясенә кергән барлык очракларда фактлагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала.

Шулай итеп, төзелеш конструкцияләренә, биналарның инженерлык системаларына һәм йорттагы башка уртак милеккә, шул

исәптән телевидениене күмәк кабул итү системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау өчен тариф билгели торган «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымтаның 4 пунктындагы дүртенче абзацы күп фатирлы йорттагы милекне тиешле хәлдә тоту хокукый механизмының бер элементы булып тора һәм кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара, чикли яки башкача боза торган итеп карала алмый һәм шуның белән Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 49 һәм 51 статьяларына каршы килми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6, 63 статьяларына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67, 68, 69, 71, 73 статьяларына һәм 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымтаның 4 пунктындагы дүртенче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Әлеге эш буенча «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 2 нче кушымтаның 4 пунктындагы дүртенче абзацының конституциячеллеген тикшерү өлешендә эш башкаруны туктатырга, чөнки мөрәҗәгать итүчеләрнең шикаятьләре бу өлештә карала алмый.

3. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

4. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы буенча бу Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 69-П

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.А. Сидлярук на нарушение ее конституционных прав и свобод подпунктом 3.1.3 Правил пользования наземным городским пассажирским транспортом общего пользования г. Казани, утвержденных решением Казанской городской Думы от 11 июня 2009 года № 9-41**

3 марта 2016 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Л.В. Кузьминой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Г.А. Сидлярук,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Г.А. Сидлярук с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод подпунктом 3.1.3 Правил пользования наземным городским пассажирским транспортом общего пользования г. Казани, утвержденных решением Казанской городской Думы от 11 июня 2009 года № 9-41 «О Правилах пользования наземным городским пассажирским транспортом общего пользования г. Казани» (далее также — Правила).

Оспариваемый подпункт 3.1.3 Правил предусматривает, что пассажиры наземного городского пассажирского транспорта общего пользования г. Казани имеют право в случае прекращения поездки в предоставленном транспортном средстве в связи с его неисправностью, аварией или другими причинами воспользоваться приобретенным билетом для проезда в другом транспортном средстве, указанном перевозчиком. Пересадка пассажиров в другое транспортное средство организуется кондуктором или водителем того транспортного средства, на проезд в котором были приобретены билеты.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, заявительница, пользуясь пассажирским транспортом общего пользования, периодически сталкивается с ситуацией, когда поездка в предоставленном транспортном средстве прекращается в связи с его неисправностью, аварией или другими причинами. Она указывает, что в данных случаях кондукторы отказываются возвращать деньги за проездной билет (а если оплата произведена с помощью валидатора, то и самого билета у нее на руках не бывает) и приходится долго ждать другое транспортное средство, указанное перевозчиком. Тем самым пассажиры зависят от конкретного пассажирского автотранспортного предприятия, транспортное средство которого оказалось неисправным.

По мнению гражданки Г.А. Сидлярук, содержащееся в оспариваемой норме понятие «перевозчик» должно истолко-

ваться как любое транспортное средство (автобус, троллейбус, трамвай), осуществляющее транспортное обслуживание населения города Казани, а не конкретное транспортное средство определенного пассажирского автотранспортного предприятия.

Как отмечает заявительница, пунктом 53 Правил перевозок пассажиров и багажа автомобильным транспортом и городским наземным электрическим транспортом, утвержденных постановлением Правительства Российской Федерации от 14 февраля 2009 года № 112, предусмотрено, что в случае прекращения поездки в предоставленном транспортном средстве в связи с его неисправностью, аварией или другими причинами пассажиры вправе воспользоваться приобретенным билетом для проезда в другом транспортном средстве, указанном перевозчиком; пересадка пассажиров в другое транспортное средство организуется кондуктором или водителем того транспортного средства, на проезд в котором были приобретены проездные билеты. Однако в соответствии с Федеральным законом от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации» создание условий для предоставления транспортных услуг населению и организация транспортного обслуживания населения относятся к вопросам местного значения муниципальных образований. В связи с чем, считает гражданка Г.А. Сидлярук, органы местного самоуправления, в том числе Казанская городская Дума, не вправе ограничиваться дублированием федерального законодательства, а должны применительно к конкретному муниципальному образованию уточнить понятие «перевозчик», а также определить допустимое время ожидания другого транспортного средства в случае прекращения поездки в предоставленном транспортном средстве, поскольку такое регулирование может устанавливаться только с учетом местных особенностей.

На основании изложенного заявительница просит Конституционный суд Республики Татарстан признать подпункт 3.1.3 Правил пользования наземным городским пассажирским транспортом общего пользования г. Казани, утвержденных решением Казанской городской Думы от 11 июня 2009 года № 9-41, противоречащим статьям 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 49 и 51 Конституции Республики Татарстан.

2. Общие условия перевозки пассажиров в Российской Федерации в силу пункта 2 статьи 784 Гражданского кодекса Российской Федерации определяются транспортными уставами и кодексами, иными законами и издаваемыми в соответствии с ними правилами.

В соответствии с частью 5 статьи 20 Федерального закона от 8 ноября 2007 года № 259-ФЗ «Устав автомобильного транспорта и городского наземного электрического транспорта» в случае невозможности осуществить перевозку пассажира и багажа предоставленным транспортным средством в связи с его неисправностью, аварией, другими аналогичными причинами пассажир имеет

право воспользоваться выданными билетом, багажной квитанцией, квитанцией на провоз ручной клади в другом транспортном средстве, предоставление которого обязан обеспечить перевозчик. Схожие правовые положения закреплены в Правилах перевозок пассажиров и багажа автомобильным транспортом и городским наземным электрическим транспортом, утвержденных постановлением Правительства Российской Федерации от 14 февраля 2009 года № 112, которыми в том числе предусмотрено, что пересадка пассажиров в другое транспортное средство организуется кондуктором или водителем того транспортного средства, на проезд в котором были приобретены билеты (пункт 53).

Оспариваемая гражданкой Г.А. Сидлярук норма принята в соответствии с приведенными федеральными нормативными правовыми актами, по своему содержанию и правовому смыслу идентична их положениям, а следовательно, не устанавливает собственного правового регулирования. Исходя из этого, проверка конституционности подпункта 3.1.3 Правил фактически означала бы оценку указанных норм федерального законодательства на их соответствие Конституции Республики Татарстан. Однако в силу статьи 109 Конституции Республики Татарстан и статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» такая проверка, равно как и внесение целесообразных, по мнению заявительницы, изменений в обжалуемые Правила, Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственна. Тем самым оспариваемая гражданкой Г.А. Сидлярук норма сама по себе не содержит неопределенности в вопросе о ее соответствии Конституции Республики Татарстан, в связи с чем согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» обращение заявительницы не является допустимым.

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктом 1 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.А. Сидлярук на нарушение ее конституционных прав и свобод подпунктом 3.1.3 Правил пользования наземным городским пассажирским транспортом общего пользования г. Казани, утвержденных решением Казанской городской Думы от 11 июня 2009 года № 9-41 «О Правилах пользования наземным городским пассажирским транспортом общего пользования г. Казани», поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями не является допустимой, а разрешение поставленных заявительницей вопросов Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Г.А. Сидлярук и в Казанскую городскую Думу.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 1-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

**Казан шәһәр Думасының 2009 елның 11 июнендәге 9-41 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы җир өсте шәһәр пассажир транспортыннан файдалану кагыйдәләренең 3.1.3 пунктчасы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.А. Сидлярук шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2016 ел
3 март
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Г.А. Сидлярук шикаятен алдан өйрәнгән судья Л.В. Кузьминаның бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.А. Сидлярук «Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы җир өсте шәһәр пассажир транспортыннан файдалану кагыйдәләре турында» Казан шәһәр Думасының 2009 елның 11 июнендәге 9-41 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы җир өсте шәһәр пассажир транспортыннан файдалану кагыйдәләренең (алга таба шулай ук — Кагыйдәләр) 3.1.3 пунктчасы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Кагыйдәләрнең дәгъвалана торган 3.1.3 пунктчасы шуны күздә тота: тәкъдим ителгән транспорт чарасында ватылу, авария яисә башка сәбәпле сәфәр өзелгән очракта Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы җир өсте шәһәр пассажир транспорты пассажирлары алынган билетлары белән алып баручы күрсәткән башка транспорт чарасыннан файдаланырга хокуклы. Пассажирларны башка транспорт чарасына күчерү эшен билет алынган транспорт чарасы кондукторы яисә йөртүчесе башкара.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче, гомуми кулланылыштагы пассажир транспортыннан файдаланып, тәкъдим ителгән транспорт чарасында ватылу, авария яисә башка сәбәпле сәфәр өзелү хәленә периодик рәвештә эләгә. Ул күрсәткәнчә, әлеге очракларда кондукторлар юл билеты өчен акчаны кайтарудан баш тарталар (ә түләү валидатор ярдәмендә башкарылган булса, билет үзе дә аның кулында булмый) һәм алып баручы күрсәткән башка транспорт чарасын озак көтәргә туры килә. Шуның белән пассажирлар транспорт чарасы ватылган конкрет пассажир автотранспорты предприятиесенә бәйле булалар.

Гражданка Г.А. Сидлярук фикеренчә, дәгъвалана торган

нормадагы «алып баручы» төшенчәсе аерым пассажир автотранспорты предприятиесенең конкрет транспорт чарасы итеп түгел, ә Казан шәһәре халкына транспорт хезмәте күрсәтә торган теләсә кайсы транспорт чарасы (автобус, троллейбус, трамвай) буларак аңлатылырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүче билгеләгәнчә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 14 февралендәге 112 номерлы карары белән расланган Пассажирларны һәм багажны автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспортында йөртү кагыйдәләренең 53 пунктында шул каралган: тәкъдим ителгән транспорт чарасында ватылу, авария яисә башка сәбәпле сәфәр өзелгән очракта пассажирлар алынган билетлары белән алып баручы күрсәткән башка транспорт чарасыннан файдаланырга хокуклы; пассажирларны башка транспорт чарасына күчерү эшен юл билеты алынган транспорт чарасы кондукторы яисә йөртүчесе башкара. Әмма «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә халыкка транспорт хезмәтләре күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм халыкка транспорт хезмәтләре күрсәтүне оештыру муниципаль берәмлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә карый. Шуңа бәйле рәвештә, гражданка Г.А. Сидлярук фикеренчә, җирле үзидарә органнары, шул исәптән Казан шәһәр Думасы, федераль законнарны кабатлау белән чикләнмәскә тиеш, ә конкрет муниципаль берәмлеккә карата «алып баручы» төшенчәсен анykларга, шулай ук тәкъдим ителгән транспорт чарасында сәфәр өзелгән очракта башка транспорт чарасын мөмкин булган көтү вакытын билгеләргә тиеш, чөнки шундый җайга салу җирле үзенчәлекләрне исәпкә алып кына урнаштырылырга мөмкин.

Бәян ителгәннәр нигезендә мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция судыннан Казан шәһәр Думасының 2009 елның 11 июнендәге 9-41 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы җир өсте шәһәр пассажир транспортыннан файдалану кагыйдәләренең 3.1.3 пунктчасын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 49 һәм 51 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясендә пассажирлар йөртүнең гомуми шартлары Россия Федерациясе Граждан кодексының 784 статьясындагы 2 пункты нигезендә транспорт уставлары һәм кодекслары, башка законнар һәм шулар нигезендә чыгарыла торган кагыйдәләр белән билгеләнәләр.

«Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 5 өлеше нигезендә тәкъдим ителгән транспорт чарасында ватылу, авария яисә башка шундый сәбәпләр аркасында пассажир һәм багажны ташу мөмкин булмаган очракта, пассажир бирелгән билет, багаж квитанциясе, кул йөген ташуга квитанция белән алып баручы тәэмин итәргә тиешле башка транспорт чарасыннан файдаланырга хокуклы. Ох-

шаш хокукый нигезләмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 14 февралендәге 112 номерлы карары белән расланган Пассажирларны һәм багажны автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспортында йөртү кагыйдәләрендә беркетелгән, алар белән пассажирларны башка транспорт чарасына күчерү эшен юл билеты алынган транспорт чарасы кондукторы яисә йөртүчесенең башкаруы шул исәптән каралган (53 пункт).

Гражданка Г.А. Сидлярук тарафыннан дәгъвалана торган норма китерелгән федераль норматив хокукый актлар нигезендә кабул ителгән, үзенең эчтәлеге һәм хокукый мәгънәсе буенча аларның нигезләмәләренә тәңгәл килә һәм, димәк, үз хокукый җайга салуын билгеләми. Моннан чыгып, Кагыйдәләрнең 3.1.3 пунктчасының конституциячеллеген тикшерү чынлыкта күрсәтелгән федераль законнар нормаларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәвенә бәя бирүне аңлатыр иде. Ләкин Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә андый тикшерү, дәгъвалана торган Кагыйдәләргә мөрәҗәгать итүче фикеренчә максатка ярашлы үзгәрешләр кертү кебек үк, Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми. Шуның белән гражданка Г.А. Сидлярук тарафыннан дәгъвалана торган нормада аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк, шуңа күрә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы җир өсте шәһәр пассажир транспортыннан файдалану кагыйдәләре турында» Казан шәһәр Думасының 2009 елның 11 июнендәге 9-41 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы җир өсте шәһәр пассажир транспортыннан файдалану кагыйдәләренең 3.1.3 пунктчасы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.А. Сидлярук шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки билгеләнгән таләпләр нигезендә шикаять карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.А. Сидлярукка һәм Казан шәһәр Думасына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 1-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.П. Караблевой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем десятым постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 23 февраля 2012 года № 153 «О внесении изменений в Положение о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденное постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 “О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан”»**

3 марта
2016 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Р.А. Сахиевой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Г.П. Караблевой,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан поступило обращение в форме жалобы гражданки Г.П. Караблевой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем десятым постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 23 февраля 2012 года № 153 «О внесении изменений в Положение о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденное постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 “О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан”». Оспариваемым заявительницей абзацем десятым вносятся изменения в пункт 2.4 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, дополняющие нормой, согласно которой предоставление субсидии-льготы приостанавливается в случае неуплаты получателем текущих платежей за жилое помещение и коммунальные услуги за период свыше 3 месяцев подряд до момента начала погашения образовавшейся задолженности или при заключении и (или) выполнении получателем соглашения по ее погашению.

Из обращения и приложенных к нему копий документов следует, что гражданка Г.П. Караблева является инвалидом и в соответствии с Федеральным законом от 24 ноября 1995 года № 181-ФЗ «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации» — получателем субсидии-льготы, выплата которой была приостановлена из-за имеющейся задолженности по оплате текущих платежей за жилое помещение и коммунальные услуги свыше трех месяцев.

Заявительница не согласна с тем, что на основании обжалуемой нормы выплата субсидий на оплату жилищно-коммунальных услуг может быть приостановлена в связи с трехмесячной задолженностью по оплате данных услуг. Она полагает, что оспариваемое положение нарушает ее конституционные права на получение этих субсидий, которые в соответствии с законодательством предоставлены ей, как инвалиду, бессрочно.

По мнению гражданки Г.П. Караблевой, обжалуемая норма не соответствует статьям 27 (часть первая), 28 (части первая и вторая), 29 (части первая и вторая), 30 Конституции Республики Татарстан.

2. Предоставление субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг предусмотрено Жилищным кодексом Российской Федерации. Согласно статье 159 данного Кодекса субсидии предоставляются гражданам при отсутствии у них задолженности по оплате жилых помещений и коммунальных услуг или при заключении и (или) выполнении гражданами соглашений по ее погашению (часть 5); порядок определения размера субсидий и порядок их предоставления, перечень прилагаемых к заявлению документов, условия приостановки и прекращения предоставления субсидий, порядок определения состава семьи получателя субсидии и исчисления совокупного дохода такой семьи, а также особенности предоставления субсидий отдельным категориям граждан устанавливаются Правительством Российской Федерации (часть 7). В развитие указанных нормативных положений постановлением Правительства Российской Федерации от 14 декабря 2005 года № 761 утверждены Правила предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг (далее — Правила), пунктом 6 которых также установлено, что субсидии предоставляются гражданам при отсутствии у них задолженности по оплате жилого помещения и коммунальных услуг или при заключении и (или) выполнении гражданами соглашений по ее погашению. При этом в соответствии с подпунктом «а» пункта 56 Правил предоставление субсидий может быть приостановлено по решению уполномоченного органа при условии неуплаты получателем субсидии текущих платежей за жилое помещение и (или) коммунальные услуги в течение 2 месяцев.

Следовательно, одним из условий предоставления гражданам субсидий является отсутствие у них задолженности по оплате жилых помещений и коммунальных услуг или заключение и (или) выполнение гражданами соглашений по ее погашению, поскольку в силу положений статьи 153 Жилищного кодекса Российской Федерации граждане обязаны своевременно и полностью вносить плату за жилое помещение и коммунальные услуги.

На основании приведенных федеральных норм Кабинет Министров Республики Татарстан постановлением от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан» утвердил Положение о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных

услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан. Между тем, установив аналогичные условия предоставления данных субсидий, Кабинет Министров Республики Татарстан в рамках своих дискреционных полномочий продлил до трех месяцев срок отсрочки исполнения обязательств по внесению платы за жилое помещение и коммунальные услуги. Вместе с тем такой подход не может рассматриваться как нарушающий конституционные права заявительницы, поскольку данное правовое регулирование по своей сути выступает в качестве дополнительной меры социальной защиты, предусматривающей более длительный период, в течение которого не допускается приостановление выплаты субсидии в случае образования задолженности по оплате жилищно-коммунальных услуг.

Таким образом, обжалуемая гражданкой Г.П. Караблевой норма в указанном ею аспекте сама по себе не содержит неопределенности в вопросе о соответствии Конституции Республики Татарстан, в связи с чем согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» обращение заявительницы не является допустимым.

На основании изложенного, руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктом 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.П. Караблевой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем десятым постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 23 февраля 2012 года № 153 «О внесении изменений в Положение о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденное постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 "О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан"», поскольку она в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Г.П. Караблевой и в Кабинет Министров Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 2-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

**«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында” 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 23 февралендәге 153 номерлы карарының унынчы абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.П. Караблева шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2016 ел
3 март
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Г.П. Караблева шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиеваның бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**а ч ы к л а д ы :**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында” 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 23 февралендәге 153 номерлы карарының унынчы абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.П. Караблеваның шикаять формасындагы мөрәҗәгате алынды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган унынчы абзац белән Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәнең 2.4 пунктына ташлама-субсидия бирү ташлама-субсидия алучы торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен агымдагы түләүләрне җыелган бурычларны каплый башлаган вакытка кадәр тоташтан 3 айдан артык чор өчен түләмәгән очракта яки ташлама-субсидия алучы аны каплау турында килешү төзегәндә һәм (яки) үтәгәндә туктатып торыла дигән норма белән тулыландыра торган үзгәрешләр кертелә.

Мөрәҗәгатьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка Г.П. Караблева — инвалид һәм «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ташлама-субсидия алучы, аны бирү торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен агымдагы түләүләр буенча өч айдан артык бурыч җыелганга күрә туктатып торылган.

Мөрәҗәгать итүче дәгъвалана торган норма нигезендә торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә субсидияләр бирүнең әлеге хезмәтләр өчен түләү буенча өч айлык бурыч җыелу сәбәпле туктатып торылу мөмкинлеге белән килешми. Ул дәгъвалана торган нигезләмә үзенең законнар нигезендә аңа, инвалид буларак, сроксыз бирелгән әлеге субсидияләрне алуга конституциячел хокукларын боза дип саный.

Гражданка Г.П. Караблева фикеренчә, дәгъвалана торган норма Татарстан Республикасы Конституциясенең 27 (беренче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче һәм икенче өлешләр), 30 статьяларына туры килми.

2. Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә субсидияләр бирү Россия Федерациясе Торак кодексында каралган. Әлеге Кодексның 159 статьясы нигезендә субсидияләр гражданнарга торак урыннар һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү буенча бурычлары булмаганда яисә гражданнар бурычны түләү турындагы килешүләрне төзегәндә һәм (яисә) үтәгәндә бирелә (5 өлеш); субсидияләр күләмен билгеләү тәртибе һәм аларны бирү тәртибе, гаризага кушып бирелә торган документлар исемлеге, субсидияләр бирүне туктатып тору һәм туктату шартлары, субсидия алучы гаиләсе составын билгеләү һәм мондый гаиләнең җыелма керемен исәпләп чыгару тәртибе, шулай ук гражданнарның аерым категорияләренә субсидияләр бирү үзенчәлекләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә (7 өлеш). Күрсәтелгән норматив нигезләмәләрне ачыклап, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 14 декабрендәге 761 номерлы карары белән Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә субсидияләр бирү кагыйдәләре (алга таба — Кагыйдәләр) расланган, аларның 6 пункты белән субсидияләр гражданнарга торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү буенча бурычлары булмаганда яисә гражданнар бурычны түләү турындагы килешүләрне төзегәндә һәм (яисә) үтәгәндә бирелә дип, шулай ук билгеләнгән. Шул ук вакытта Кагыйдәләрнең 56 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә субсидияләр бирү субсидия алучы торак урын һәм (яки) коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен агымдагы түләүләрне 2 ай дәвамында түләмәгән очракта вәкаләтле орган карары белән туктатып торылырга мөмкин.

Димәк, гражданнарга субсидия бирүнең бер шарты булып аларның торак урыннар һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү буенча бурычлары булмавы яисә гражданнарның бурычны түләү турындагы килешүләрне төзүе һәм (яисә) үтәве тора,

чөнки Россия Федерациясе Торак кодексының 153 статьясы нигезләмәләре буенча гражданнар торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүне үз вакытында һәм тулысынча кертергә тиеш.

Китерелгән федераль нормалар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслаган. Шул ук вакытта әлеге субсидияләрне бирүнең тиңдәш шартларын билгеләп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең дискрецион вәкаләтләре кысаларында торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү йөкләмәсен кичектерү вакытын өч айга кадәр озайткан. Шуның белән бергә мондый алым мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын боза торган итеп карала алмый, чөнки әлеге хокукый җайга салу үзенең асылы буенча, торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү буенча бурыч барлыкка килгән очракта, субсидия бирү туктатып торылу рөхсәт ителмәгән озынрак вакыт билгели торган өстәмә социаль яклау чарасы булып тора.

Шулай итеп, гражданка Г.П. Караблева тарафыннан дәгъвалана торган нормада ул күрсәткән аспектта Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәү мәсьәләсендә билгесезлек юк, шуңа күрә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында” 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 23 февралендәге 153 номерлы карарының унынчы аб-

зацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.П. Караблева шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә шикаять карала алмый.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.П. Караблевага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 2-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.А. Сидлярук на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 3 Порядка предоставления единого месячного социального проездного билета и единого месячного детского социального проездного билета в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 7 апреля 2005 года № 161**

21 марта
2016 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Р.Ф. Гафиятуллина, проводившего на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Г.А. Сидлярук,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Г.А. Сидлярук с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 3 Порядка предоставления единого месячного социального проездного билета и единого месячного детского социального проездного билета в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 7 апреля 2005 года № 161 «Об утверждении Порядка предоставления единого месячного социального проездного билета и единого месячного детского социального проездного билета в Республике Татарстан».

Оспариваемый пункт указанного Порядка определяет категории граждан, которым предоставляется право на приобретение единого месячного социального проездного билета и единого месячного детского социального проездного билета.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, гражданка Г.А. Сидлярук, являющаяся матерью двух несовершеннолетних детей, считает, что в перечень данных категорий граждан необоснованно не включены учащиеся и студенты. В целях реализации права на предоставление ее детям субсидии на приобретение льготного проездного билета она неоднократно обращалась в Исполнительный комитет муниципального образования города Казани, к депутатам Государственного Совета Республики Татарстан, а также в иные органы государственной власти Республики Татарстан. Из ответов на ее обращения следует, что перечень лиц в Республике Татарстан, имеющих льготы по оплате проезда в наземном городском общественном транспорте, определен законодательно. В соответствии с действующим законодательством приобрести детский проездной билет имеют право дети-инвалиды; дети из многодетных семей, обучающиеся в общеобразовательных учреждениях и учреждениях начального и среднего профессионального образования, до окончания ими обучения, но не более

чем до достижения ими восемнадцати лет; дети-сироты и дети, оставшиеся без попечения родителей, и лица из числа детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, обучающиеся в образовательных учреждениях.

В обоснование своей позиции заявительница ссылается на то, что действовавшее до принятия Федерального закона от 22 августа 2004 года № 122-ФЗ правовое регулирование предусматривало возможность предоставления льготного проездного билета всем категориям учащихся и студентов независимо от их имущественного и социального положения. Кроме того, по мнению заявительницы, подобная мера социальной поддержки действует в настоящее время в отдельных муниципальных образованиях в Республике Татарстан.

На основании изложенного гражданка Г.А. Сидлярук просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункт 3 Порядка предоставления единого месячного социального проездного билета и единого месячного детского социального проездного билета в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 7 апреля 2005 года № 161, не соответствующим Конституции Республики Татарстан, ее статьям 27 (часть первая), 28 (части первая и вторая), 29 (части первая и вторая), 30, 32 и 38 (часть первая).

2. Федеральным законом от 6 октября 1999 года № 184-ФЗ «Об общих принципах организации законодательных (представительных) и исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации» (в редакции Федерального закона от 31 декабря 2005 года № 199-ФЗ) предусмотрено, что органы государственной власти субъекта Российской Федерации вправе устанавливать за счет средств бюджета субъекта Российской Федерации (за исключением финансовых средств, передаваемых из федерального бюджета бюджету субъекта Российской Федерации на осуществление целевых расходов) дополнительные меры социальной поддержки и социальной помощи для отдельных категорий граждан вне зависимости от наличия в федеральных законах положений, устанавливающих указанное право. Финансирование полномочий, предусмотренное данной статьей, не является обязанностью субъекта Российской Федерации, осуществляется при наличии возможности и не является основанием для выделения дополнительных средств из федерального бюджета (части 3 и 4 статьи 26.3-1).

Категории граждан, которым предоставляются меры адресной социальной поддержки в Республике Татарстан, а также конкретные объемы и формы их предоставления определены в Законе Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан». Применительно к детям, согласно статье 2 указанного Закона Республики Татарстан, меры адресной социальной поддержки, к числу которых относится и субсидия на проезд, предоставляются детям-сиротам, детям, оставшимся без попечения родителей, лицам из числа детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей. Тем самым, утверждая оспариваемый Порядок, Кабинет Мини-

стров Республики Татарстан установил организационно-правовой механизм реализации права на предоставление меры социальной поддержки, основания и критерии получения которой урегулированы на законодательном уровне.

Таким образом, по своему целевому назначению обжалуемое правовое регулирование принято во исполнение Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан», не устанавливает каких-либо дополнительных необоснованных условий приобретения единого месячного социального проездного билета и единого месячного детского социального проездного билета и тем самым не содержит неопределенности в вопросе о соответствии Конституции Республики Татарстан. Разрешение же поставленного заявительницей вопроса о распространении права на приобретение единого месячного социального проездного билета и единого месячного детского социального проездного билета на всех учащихся и студентов в Республике Татарстан предполагает внесение изменений в действующее законодательство, что входит в компетенцию законодателя и не относится к полномочиям Конституционного суда Республики Татарстан, как они определены в статье 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного, руководствуясь частью пятой статьи 3, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72 и 73 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.А. Сидлярук на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 3 Порядка предоставления единого месячного социального проездного билета и единого месячного детского социального проездного билета в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 7 апреля 2005 года № 161 «Об утверждении Порядка предоставления единого месячного социального проездного билета и единого месячного детского социального проездного билета в Республике Татарстан», поскольку разрешение поставленных заявительницей вопросов Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно и жалоба в соответствии с установленными требованиями не является допустимой.
2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.
3. Копию настоящего Определения направить гражданке Г.А. Сидлярук и в Кабинет Министров Республики Татарстан.
4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 4-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 7 апрелендәге 161 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенең 3 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.А. Сидлярук шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2016 ел
21 март
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Г.А. Сидлярук шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Ф. Гафиятуллинның бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.А. Сидлярук «Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 7 апрелендәге 161 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенең 3 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Күрсәтелгән Тәртипнең дәгъвалана торган пункты транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет алу хокукы бирелә торган гражданнар категорияләрен билгели.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, балигъ булмаган ике бала анасы булган гражданка Г.А. Сидлярук әлеге гражданнар категорияләре исемлегенә укучылар һәм студентлар нигезсез кертелмәгән дип саный. Үз балаларына ташламалы юл йөрү билетын алуга субсидия бирү хокукын гамәлгә ашыру максатларында ул берничә тапкыр Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнарына мөрәҗәгать иткән. Аның мөрәҗәгатьләренә бирелгән җаваплардан аңлашылганча, җир өсте шәһәр җәмәгать транспортында йөрү бәясен түләү буенча ташламаларга ия булган затлар исемлеге законнар белән билгеләнгән. Гамәлдәге законнар нигезендә балалар юл йөрү билетын инвалид балалар; гомуми белем бирү учреждениеләрендә һәм башлангыч

һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучы күп балалы гаиләләрдән булган балалар укулары тәмамланганчыга кадәр, ләкин унсигез яшькә җиткәнчегә кадәр генә; белем бирү учреждениеләрендә укучы ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар исәбеннән булган затлар алырга хокуклы.

Үз позициясен нигезләп, мөрәҗәгать итүче 2004 елның 22 августындагы 122-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителгәнчегә кадәр гамәлдә булган хокукый җайга салуның ташламалы юл йөрү билетын укучы һәм студентларның барлык категорияләренә, аларның мөлкәти һәм социаль хәлләренә карамастан, бирү мөмкинлеген күздә тотканлыгын күрсәтә. Моннан тыш, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, мондый социаль ярдәм күрсәтү чарасы хәзерге вакытта Татарстан Республикасындагы аерым муниципаль берәмлекләрдә гамәлдә.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Г.А. Сидлярук Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 7 апрелендәге 161 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенең 3 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенә, аның 27 (беренче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче һәм икенче өлешләр), 30, 32 һәм 38 (беренче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законда (2005 елның 31 декабрендәге 199-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) каралганча, Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары хисабына (федераль бюджеттан максатчан чыгымнарны тормышка ашыру өчен Россия Федерациясе субъекты бюджетына тапшырыла торган финанс чараларыннан тыш) гражданнарның аерым категорияләре өчен социаль ярдәм күрсәтүнең һәм социаль булышуның өстәмә чараларын билгеләргә хокуклы, бу федераль законнарда әлеге хокукны билгели торган нигезләмәләрнең булу-булмавына бәйле түгел. Әлеге статьяда каралган вәкаләтләрне финанслау Россия Федерациясе субъектының бурычы булып тормый, мөмкинлек булганда гамәлгә ашырыла һәм федераль бюджеттан өстәмә акча бүлеп бирү өчен нигез булып тормый (26.3-1 статьяның 3 һәм 4 өлешләре).

Татарстан Республикасында адреслы социаль ярдәм чаралары күрсәтелә торган гражданнар категорияләре, шулай ук аларны бирүнең конкрет күләмнәре һәм рәвешләре «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән. Аталган Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә балаларга карата адреслы со-

циаль ярдәм күрсәтү чаралары, алар исәбенә транспортта йөрү өчен субсидия дә керә, ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар исәбеннән булган затларга күрсәтелә. Шуның белән, дәгъвалана торган Тәртипне раслап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты социаль ярдәм чарасын күрсәтүгә хокукны гамәлгә ашыруның оештыру-хокукый механизмын билгеләгән, ярдәм алуның нигезләре һәм критерийлары законнар дәрәҗәсендә җайга салынган.

Шулай итеп, үзенең максатчан билгеләнеше буенча дәгъвалана торган хокукый җайга салу «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән кабул ителгән, транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет алуның нинди дә булса өстәмә нигезсез шартларын билгеләми һәм шуның белән аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет алуга хокукны Татарстан Республикасындагы барлык укучыларга һәм студентларга да кагылдыру турындагы мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү гамәлдәге законнарга үзгәрешләр кертүне күздә тота, бу исә закон чыгаручы компетенциясенә керә һәм Татарстан Республикасы Конституция судының «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгән вәкаләтләренә карамый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче өлешенә, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72 һәм 73 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 7 апрелендәге 161 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенең 3 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.А. Сидлярук шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми һәм билгеләнгән таләпләр нигезендә шикаять карала алмый.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.А. Сидлярукка һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 4-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

26 апреля 2016 года
город Казань

**об отказе в принятии к рассмотрению обращения гражданина Н.Ш. Валиева по вопросам, связанным с предоставлением ему субсидий на оплату жилья и коммунальных услуг**

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Р.А. Сахиевой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение обращения гражданина Н.Ш. Валиева,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан поступило обращение гражданина Н.Ш. Валиева по вопросам, связанным с предоставлением ему субсидий на оплату жилья и коммунальных услуг, в частности о признании действий и решений отдела социальной защиты Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан в Чистопольском муниципальном районе не соответствующими Конституции Республики Татарстан и восстановлении его конституционных прав как пенсионера — ветерана труда.

В соответствии со статьей 43 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» аппарат Конституционного суда Республики Татарстан неоднократно уведомлял гражданина Н.Ш. Валиева о том, что его жалобы не соответствуют требованиям, предъявляемым данным Законом к обращениям граждан, и не могут быть приняты к рассмотрению ввиду их явной неподведомственности Конституционному суду Республики Татарстан.

Однако гражданин Н.Ш. Валиев на основании части второй статьи 43 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» настаивает на принятии решения Конституционным судом Республики Татарстан по поставленным им вопросам.

2. Согласно статье 109 (часть четвертая) Конституции Республики Татарстан, частям пятой и девятой статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционный суд Республики Татарстан по жалобам граждан на нарушение их конституционных прав и свобод проверяет конституционность закона Республики Татарстан или его отдельных положений, нормативных правовых актов Президента и Кабинета Министров Республики Татарстан, а также органов местного самоуправления. Конституционный суд Республики Татарстан решает исключительно вопросы права и при осуществлении конституционного судопроизводства воздерживается от установления

и исследования фактических обстоятельств во всех случаях, когда это входит в компетенцию других судов или иных органов государственной власти Республики Татарстан.

В своем обращении гражданин Н.Ш. Валиев не оспаривает конституционность нормативных правовых актов, а ставит вопросы, которые не входят в полномочия Конституционного суда Республики Татарстан, как они определены статьей 109 Конституции Республики Татарстан и статьей 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

Из этого следует, что разрешение вопросов, поставленных в его обращении, явно неподведомственно Конституционному суду Республики Татарстан.

На основании изложенного, руководствуясь пунктом 1 части второй статьи 43, пунктом 1 части первой статьи 46 и статьей 73 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению обращения гражданина Н.Ш. Валиева, поскольку разрешение поставленных в нем вопросов явно неподведомственно Конституционному суду Республики Татарстан.
2. В соответствии с подпунктом 2 пункта 1 статьи 333.40 Налогового кодекса Российской Федерации государственная пошлина, уплаченная гражданином Н.Ш. Валиевым, подлежит возврату полностью.
3. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данному обращению окончательно и обжалованию не подлежит.
4. Копию настоящего Определения направить гражданину Н.Ш. Валиеву.
5. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 6-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

**гражданин Н.Ш. Вәлиевның аңа торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр бирү белән бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгатен карауга алудан баш тарту турында**

2016 ел
26 апрель
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин Н.Ш. Вәлиев мөрәҗәгатен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин Н.Ш. Вәлиевтан аңа торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр бирү белән бәйле мәсьәләләр буенча, аерым алганда, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Чистай муниципаль районындагы социаль яклау бүлегенең гамәлләре һәм карарларын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тану һәм үзенең пенсионер — хезмәт ветераны буларак конституциячел хокукларын торгызу турында мөрәҗәгать килде.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 43 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды аппараты гражданин Н.Ш. Вәлиевка аның шикаятьләре гражданнар мөрәҗәгатьләренә карата әлеге Закон куйган таләпләргә туры килми һәм, Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына ачыктан-ачык кермәгәнлектән, карауга алына алмый дип берничә тапкыр хәбәр иткән иде.

Ләкин гражданин Н.Ш. Вәлиев «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 43 статьясындагы икенче өлеше нигезендә үзе куйган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан карар кабул итүне таләп итә.

2. Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы (дүртенче өлеш) һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаятьләре буенча Татарстан Республикасы законының яисә аның аерым нигезләмәләренең, Татарстан Республикасы Президенты һәм Министрлар Кабинеты, шулай ук җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларының конституциячеллеген тикшерә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик хокук

мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары компетенциясенә кергән барлык очракларда факттагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала.

Үз мөрәҗәгатендә гражданин Н.Ш. Вәлиев норматив хокукый актларның конституциячеллегенә карата дәгъва белдерми, ә Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы белән билгеләнгән вәкаләтләренә кермәгән мәсьәләләрне куя.

Моннан чыгып, аның мөрәҗәгатендә куелган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына ачыктан-ачык керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 43 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына һәм 73 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Гражданин Н.Ш. Вәлиев мөрәҗәгатен карауга алудан баш тартырга, чөнки анда куелган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына ачыктан-ачык керми.

2. Россия Федерациясе Салым кодексының 333.40 статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасы нигезендә гражданин Н.Ш. Вәлиев түләгән дәүләт пошлинасы тулысынча кайтарылырга тиеш.

3. Бу мөрәҗәгать буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

4. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин Н.Ш. Вәлиевка җибәрергә.

5. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 6-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданина А.А. Кормилина на нарушение его конституционных прав и свобод подпунктом 2 пункта 3 решения Лениногорского районного Совета муниципального образования «Лениногорский муниципальный район» Республики Татарстан от 15 октября 2008 года № 64 «О порядке предоставления жилых помещений муниципального специализированного жилищного фонда Лениногорского муниципального района», а также пунктами 1 и 1.2 Положения о порядке предоставления жилых помещений муниципального специализированного жилищного фонда Лениногорского муниципального района, утвержденного данным решением**

2 июня 2016 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Р.Ф. Гафиятуллина, проводившего на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданина А.А. Кормилина,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан поступили жалоба гражданина А.А. Кормилина и дополнение к ней на нарушение его конституционных прав и свобод подпунктом 2 пункта 3 решения Лениногорского районного Совета муниципального образования «Лениногорский муниципальный район» Республики Татарстан от 15 октября 2008 года № 64 «О порядке предоставления жилых помещений муниципального специализированного жилищного фонда Лениногорского муниципального района» (далее также — Решение), а также пунктами 1 и 1.2 Положения о порядке предоставления жилых помещений муниципального специализированного жилищного фонда Лениногорского муниципального района, утвержденного данным решением (далее также — Положение).

Подпунктом 2 пункта 3 Решения предусмотрено, что Исполнительному комитету муниципального образования «Лениногорский муниципальный район» поручено привести свои нормативные правовые акты по специализированному жилищному фонду в соответствие с данным Решением.

Пунктом 1 Положения определено, что оно разработано в соответствии с нормами Жилищного кодекса Российской Федерации и постановлением Правительства Российской Федерации от 26 января 2006 года № 42 «Об утверждении Правил отнесения жилого помещения к специализированному жилищному фонду и типовых договоров найма специализированных жилых помещений» и устанавливает порядок предоставления жилых помещений муниципального специализированного жилищного фонда Лениногорского муниципального района.

Пунктом 1.2 Положения предусмотрено, что включение жилого

помещения в специализированный жилищный фонд с отнесением такого помещения к определенному виду специализированного жилищного фонда и исключение из него осуществляются на основании постановления Исполнительного комитета муниципального образования «Лениногорский муниципальный район» с учетом требований постановления Правительства Российской Федерации от 26 января 2006 года № 42.

Как следует из жалобы, дополнения к ней и приложенных копий документов, квартира, расположенная в городе Лениногорске, в которой заявитель проживает с супругой и двумя несовершеннолетними детьми, распоряжением заместителя главы администрации по городу Лениногорску от 7 сентября 1998 года № 843 была переведена в разряд общежития, а впоследствии передана в муниципальную собственность на основании договора о закреплении муниципального имущества на праве оперативного управления за муниципальным учреждением.

Решением Лениногорского городского суда Республики Татарстан от 29 ноября 2012 года в удовлетворении исковых требований заявителя о признании за ним и членами его семьи права на приватизацию 1/2 части указанной квартиры, о понуждении к заключению договора приватизации жилого помещения, о признании решения Лениногорского районного Совета муниципального образования «Лениногорский муниципальный район» об определении статуса жилого помещения незаконным, а также об определении доли в праве собственности мест общего пользования в жилом помещении было отказано.

Гражданин А.А. Кормилин полагает, что в связи с принятием обжалуемого Решения проживающие в данной квартире жильцы фактически лишены права на приватизацию квартиры.

Кроме того, заявитель указывает на то, что пункт 1.2 Положения нарушает его конституционные права и свободы, поскольку не устанавливает критерии включения жилого помещения в специализированный жилищный фонд с отнесением такого помещения к определенному виду специализированного жилищного фонда и исключения из него, что приводит к злоупотреблениям при его реализации. По его мнению, Исполнительный комитет Лениногорского муниципального района, используя отсутствие в оспариваемой норме указанных критериев и оснований, не исключил жилое помещение, в котором он проживает с семьей, из специализированного жилищного фонда, что не дает ему возможность приватизировать данную квартиру.

На основании вышеизложенного гражданин А.А. Кормилин считает, что оспариваемые нормы нарушают его конституционные права и свободы, и просит Конституционный суд Республики Татарстан признать их не соответствующими статьям 49 и 55 Конституции Республики Татарстан.

2. В соответствии со статьей 109 (часть четвертая) Конституции Республики Татарстан, частями пятой и девятой статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционный суд Республики Татарстан по жалобам

граждан на нарушение их конституционных прав и свобод проверяет конституционность законов Республики Татарстан или их отдельных положений, нормативных правовых актов Президента и Кабинета Министров Республики Татарстан, а также органов местного самоуправления. Конституционный суд Республики Татарстан решает исключительно вопросы права и при осуществлении конституционного судопроизводства воздерживается от установления и исследования фактических обстоятельств во всех случаях, когда это входит в компетенцию других судов или иных органов государственной власти Республики Татарстан.

По своему содержанию подпункт 2 пункта 3 Решения предусматривает организационно-распорядительные меры общего действия, направленные на приведение правовых актов Исполнительного комитета муниципального образования «Лениногорский муниципальный район» по специализированному жилищному фонду в соответствие с указанным Решением. Тем самым подпункт 2 пункта 3 Решения не устанавливает новых норм права, не изменяет и не отменяет действующие правовые нормы и, следовательно, не относится к категории нормативных актов, рассматриваемых Конституционным судом Республики Татарстан в порядке, установленном пунктом 3 части первой статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

Согласно постановлению Правительства Российской Федерации от 26 января 2006 года № 42 «Об утверждении Правил отнесения жилого помещения к специализированному жилищному фонду и типовых договоров найма специализированных жилых помещений» включение жилого помещения в специализированный жилищный фонд с отнесением такого помещения к определенному виду жилых помещений специализированного жилищного фонда и исключение жилого помещения из указанного фонда производятся на основании решения органа, осуществляющего управление государственным или муниципальным жилищным фондом, с учетом требований, установленных Правилами отнесения жилого помещения к специализированному жилищному фонду, утвержденными указанным постановлением (пункт 12).

Пункт 1 Положения указывает на то, что оно разработано в соответствии с нормами Жилищного кодекса Российской Федерации и вышеуказанным постановлением Правительства Российской Федерации. Пунктом 1.2 Положения предусмотрено, что включение жилого помещения в специализированный жилищный фонд с отнесением такого помещения к определенному виду специализированного жилищного фонда и исключение из него осуществляются на основании постановления Исполнительного комитета муниципального образования «Лениногорский муниципальный район» с учетом требований указанного постановления Правительства Российской Федерации.

Таким образом, оспариваемые пункты 1 и 1.2 Положения по своей сути воспроизводят нормы постановления Правительства Российской Федерации от 26 января 2006 года № 42 «Об утверждении Правил отнесения жилого помещения к специализированному

жилищному фонду и типовых договоров найма специализированных жилых помещений». Исходя из этого, проверка конституционности обжалуемых положений фактически означала бы оценку указанных норм федерального законодательства на их соответствие Конституции Республики Татарстан, что также Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

На этом основании разрешение поставленного заявителем вопроса о проверке конституционности подпункта 2 пункта 3 Решения и пунктов 1 и 1.2 Положения в полномочия Конституционного суда Республики Татарстан, как они определены статьей 109 Конституции Республики Татарстан и статьей 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», не входит.

На основании изложенного, руководствуясь частью пятой статьи 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**о п р е д е л и л :**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданина А.А. Кормилина на нарушение его конституционных прав и свобод подпунктом 2 пункта 3 решения Лениногорского районного Совета муниципального образования «Лениногорский муниципальный район» Республики Татарстан от 15 октября 2008 года № 64 «О порядке предоставления жилых помещений муниципального специализированного жилищного фонда Лениногорского муниципального района», а также пунктами 1 и 1.2 Положения о порядке предоставления жилых помещений муниципального специализированного жилищного фонда Лениногорского муниципального района, утвержденного данным решением, поскольку разрешение поставленных заявителем вопросов Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно и жалоба в соответствии с установленными требованиями не является допустимой.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданину А.А. Кормилину и в Исполнительный комитет муниципального образования «Лениногорский муниципальный район» Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 10-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

**«Лениногорск муниципаль районы махсус муниципаль торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында» 2008 елның 15 октябрендәге 64 номерлы Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Лениногорск район Советы карарының 3 пунктындагы 2 пунктчасы, шулай ук әлеге карар белән расланган Лениногорск муниципаль районы махсус муниципаль торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында нигезләмәнең 1 һәм 1.2 пунктлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин А.А. Кормилин шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2016 ел
2 июнь
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин А.А. Кормилин шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Ф. Гафиятуллин бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**а ч ы к л а д ы :**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына «Лениногорск муниципаль районы махсус муниципаль торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында» 2008 елның 15 октябрендәге 64 номерлы Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Лениногорск район Советы карарының (алга таба шулай ук — Карар) 3 пунктындагы 2 пунктчасы, шулай ук әлеге карар белән расланган Лениногорск муниципаль районы махсус муниципаль торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында нигезләмәнең (алга таба шулай ук — Нигезләмә) 1 һәм 1.2 пунктлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин А.А. Кормилин шикаяте һәм шуңа өстәмә алынды.

Карарның 3 пунктындагы 2 пунктчасы белән «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына махсус торак фонды буенча үзенең норматив хокукый актларын әлеге Карар белән тәңгәлләштерү йөкләнә дип каралган.

Нигезләмәнең 1 пункты белән шул билгеләнгән: ул Россия Федерациясе Торак кодексы нормалары һәм «Торак урынны махсус торак фонды исәбенә кертү кагыйдәләрен һәм махсус торак урыннарына бер типтагы наем шартнамәләрен раслау турында» 2006 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә эшләнгән һәм Лениногорск муниципаль районы махсус муниципаль торак фондының торак урыннарын бирү тәртибен билгели.

Нигезләмәнең 1.2 пунктында каралганча, торак урынны махсус торак фондының аерым төре исәбенә кертеп, андый урынны махсус торак фондына кертү һәм аннан чыгару «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма коми-

теты карары нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы карары таләпләрен исәпкә алып башкарыла.

Шикаятьтән, аңа өстәмәдән һәм кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче хатыны һәм ике балигъ булмаган баласы белән яшәгән Лениногорск шәһәрендә урнашкан фатир Лениногорск шәһәре буенча администрация башлыгы урынбасарының 1998 елның 7 сентябрендәге 843 номерлы күрсәтмәсе белән тулай торак исәбенә күчерелгән, ә соңыннан оператив идарә итү хокукында муниципаль мөлкәтне муниципаль учреждениегә беркетү турындагы шартнамә нигезендә муниципаль милеккә тапшырылган.

Татарстан Республикасы Лениногорск шәһәр судының 2012 елның 29 ноябрендәге карары белән мөрәҗәгать итүченең аның һәм гаилә әгъзаларының күрсәтелгән фатирның 1/2 өлешен хосусыйлаштыруга хокукын тану, торак урынны хосусыйлаштыру шартнамәсен төзергә мәҗбүр итү, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Лениногорск район Советының торак урынның статусын билгеләү хакындагы карарын законсыз дип тану, шулай ук торак урындагы гомуми кулланылыштагы урыннарга милек хокукындагы өлешне билгеләү турындагы дәгъва таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тартылган.

Гражданин А.А. Кормилин фикеренчә, дәгъвалана торган Карарны кабул итү сәбәпле, әлеге фатирда яшәүчеләр асылда фатирны хосусыйлаштыру хокукыннан мәхрүм ителгәннәр.

Моннан тыш, мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, Нигезләмәнең 1.2 пункты аның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза, чөнки ул торак урынны махсус торак фондының аерым төре исәбенә кертеп, андый урынны махсус торак фондына кертү һәм аннан чыгару критерийларын билгеләми, бу исә аны кулланганда төрле бозуларга китерә. Аның фикеренчә, Лениногорск муниципаль районы Башкарма комитеты дәгъвалана торган нормада күрсәтелгән критерийлар һәм нигезләрнең булмавыннан файдаланып, ул гаиләсе белән яшәгән торак урынны махсус торак фондыннан чыгармаган, ә бу аңа әлеге фатирны хосусыйлаштырырга мөмкинлек бирми.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә гражданин А.А. Кормилин дәгъвалана торган нормалар аның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза дип саный һәм Татарстан Республикасы Конституция судыннан аларны Татарстан Республикасы Конституциясенең 49 һәм 55 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы (дүртенче өлеш) һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаятьләре буенча Татарстан Республикасы законнарының яисә аларның аерым нигезләмәләренең, Татарстан Республикасы Президенты һәм Ми-

нистрлар Кабинеты, шулай ук җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларының конституциячеллеген тикшерә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары компетенциясенә кергән барлык очракларда факттагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала.

Карарның 3 пунктындагы 2 пунктчасы үзенең эчтәлеге буенча «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының махсус торак фонды буенча хокукый актларын күрсәтелгән Карар белән тәңгәлләштерүгә юнәлдерә торган гомуми гамәлдәге оештыру-боеру чараларын күздә тота. Шул рәвешле Карарның 3 пунктындагы 2 пунктчасы яңа хокук нормаларын билгеләми, гамәлдәге хокукый нормаларны үзгәртми һәм юкка чыгармый һәм, димәк, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы Конституция суды карый торган норматив актлар категориясенә карамый.

«Торак урынны махсус торак фонды исәбенә кертү кагыйдәләрен һәм махсус торак урыннарына бер типтагы наем шартнамәләрен раслау турында» 2006 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары буенча торак урынны махсус торак фондының аерым төре исәбенә кертеп, андый урынны махсус торак фондына кертү һәм торак урынны күрсәтелгән фондтан чыгару дәүләт яки муниципаль торак фонды белән идарә итүне гамәлгә ашыра торган орган карары нигезендә күрсәтелгән карар белән расланган Торак урынны махсус торак фонды исәбенә кертү кагыйдәләре билгеләгән таләпләрне исәпкә алып башкарыла (12 пункт).

Нигезләмәнең 1 пункты аның Россия Федерациясе Торак кодексы нормалары һәм югарыда аталган Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә эшләнгәнен күрсәтә. Нигезләмәнең 1.2 пункты белән торак урынны махсус торак фондының аерым төре исәбенә кертеп, андый урынны махсус торак фондына кертү һәм аннан чыгару «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең күрсәтелгән карары таләпләрен исәпкә алып башкарыла дип күздә тотыла.

Шулай итеп, Нигезләмәнең дәгъвалана торган 1 һәм 1.2 пунктлары үзләренең асылы буенча «Торак урынны махсус торак фонды исәбенә кертү кагыйдәләрен һәм махсус торак урыннарына бер типтагы наем шартнамәләрен раслау турында» 2006 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нормаларын кабатлыйлар. Моннан чыгып, дәгъвалана торган нигезләмәләрнең конституциячеллеген тикшерү чынлыкта федераль законнардагы күрсәтелгән нормаларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәвенә бәя бирүне аңлатыр иде, бу исә Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына шулай ук керми.

Болар нигезендә Карарның 3 пунктындагы 2 пунктчасының һәм Нигезләмәнең 1 һәм 1.2 пунктларының конституциячеллеген тикшерү турында мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы белән билгеләнгән вәкаләтләренә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче өлешенә, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Лениногорск муниципаль районы махсус муниципаль торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында» 2008 елның 15 октябрендәге 64 номерлы Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Лениногорск район Советы карарының 3 пунктындагы 2 пунктчасы, шулай ук әлеге карар белән расланган Лениногорск муниципаль районы махсус муниципаль торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында нигезләмәнең 1 һәм 1.2 пунктлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин А.А. Кормилин шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми һәм билгеләнгән таләпләр нигезендә шикаять карала алмый.
2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.
3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин А.А. Кормилинга һәм Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрергә.
4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 10-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Р.Х. Кашаповой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 2 приложения № 1 и пунктом 2 приложения № 2 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год»**

6 июня
2016 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи А.Р. Шакараева, проводившего на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Р.Х. Кашаповой,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Р.Х. Кашапова с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 2 приложения № 1 и пунктом 2 приложения № 2 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год». Данным постановлением утвержден и введен в действие размер платы за содержание жилых помещений для нанимателей жилых помещений по договорам социального найма и договорам найма жилых помещений государственного или муниципального жилищного фонда, а также собственников помещений в многоквартирных домах, не принявших решения о выборе способа управления многоквартирным домом и (или) на общем собрании решения об установлении размера платы за содержание жилых помещений, по видам услуг на период с 1 января 2016 года по 30 июня 2016 года (приложение № 1) и с 1 июля 2016 года по 31 декабря 2016 года (приложение № 2). Оспариваемыми положениями установлено, что тариф за управление многоквартирным домом составляет 2,70 руб. с 1 кв. метра общей площади жилого помещения в месяц.

Как следует из жалобы, дополнения к ней и приложенных к ним копий документов, заявительница является собственником жилого помещения в многоквартирном доме, который с 2016 года находится в управлении УК «Жилищник-4» (ранее дом находился в управлении ТСЖ «Азино-1»). Гражданка Р.Х. Кашапова указывает, что в текущем году в соответствии с обжалуемыми нормами за управление многоквартирным домом она должна платить 2,70 руб. с 1 кв. метра общей площади жилого помещения в месяц. По ее мнению, в эту сумму включена плата за услуги общества

с ограниченной ответственностью «Единый расчетный центр г. Казани» (далее — ООО «ЕРЦ г. Казани»), размер которой для их многоквартирного дома составляет 1,23 руб. с 1 кв. метра общей площади жилого помещения в месяц.

Заявительница полагает, что без посреднических услуг ООО «ЕРЦ г. Казани» она бы платила за управление многоквартирным домом значительно меньшую сумму. В этой связи она обратилась в Исполнительный комитет муниципального образования города Казани. Из содержания ответа на ее обращение следует, что ООО «ЕРЦ г. Казани» создано с целью максимально полного соблюдения законодательства в порядке проведения расчетов за коммунальные и иные услуги между управляющими организациями, поставщиками услуг и собственниками помещений, а средства, собираемые по услуге «Управление многоквартирным домом», идут на обработку показаний приборов учета, формирование и распечатку счетов-фактур, обобщение сведений о платежах, подготовку документов для постановки граждан на регистрационный учет, ведение договорных отношений с коммунальными предприятиями, претензионную работу и т.д.

Однако заявительница считает, что в посреднических функциях ООО «ЕРЦ г. Казани» нет никакой необходимости, поскольку в соответствии с действующим федеральным законодательством граждане имеют право вносить плату за содержание жилых помещений и коммунальные услуги напрямую управляющей организации без участия платежного агента.

На основании изложенного гражданка Р.Х. Кашапова просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункт 2 приложения № 1 и пункт 2 приложения № 2 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год» в той мере, в какой они включают в тариф за управление многоквартирным домом содержание ООО «ЕРЦ г. Казани», не соответствующими статьям 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 49, 51 и 55 Конституции Республики Татарстан.

2. В силу пункта 1 части 2 статьи 154 Жилищного кодекса Российской Федерации в структуру платы за жилое помещение и коммунальные услуги для собственника помещения в многоквартирном доме входит плата за содержание жилого помещения, включающая в себя плату за услуги, работы по управлению многоквартирным домом. Исходя из смысла частей 7 и 8 статьи 156 указанного Кодекса, размер платы за содержание и ремонт жилого помещения для собственников жилых и нежилых помещений устанавливается на общем собрании собственников помещений в многоквартирном доме или органами управления товарищества собственников жилья либо органами управления жилищного кооператива или органами управления иного специализированного потребительского кооператива. Между тем, закрепляя на законодательном уровне приоритет на право регу-

лирования ценообразования в жилищной сфере за собственниками помещений в многоквартирном доме, Жилищный кодекс Российской Федерации в силу части 3 статьи 156 и части 4 статьи 158 предусматривает, что если собственники жилых помещений не приняли решение о выборе способа управления многоквартирным домом и (или) на их общем собрании не приняли решение об установлении размера платы за содержание жилого помещения, такой размер устанавливается органом местного самоуправления.

Как указывал Конституционный Суд Российской Федерации, наделение органов местного самоуправления в соответствии с частью 4 статьи 158 Жилищного кодекса Российской Федерации полномочием по установлению размера платы за содержание и ремонт жилого помещения в многоквартирном доме не препятствует осуществлению собственниками помещений в многоквартирном доме права по самостоятельному установлению данной платы, так как реализация указанного полномочия органов местного самоуправления обусловлена отсутствием соответствующего волеизъявления собственников помещений в многоквартирном доме. Оспариваемое законоположение направлено на обеспечение надлежащего функционирования жилищно-коммунального хозяйства, что соответствует интересам как собственников помещений в многоквартирном доме, так и иных участников жилищных правоотношений; часть 4 статьи 158 Жилищного кодекса Российской Федерации не предполагает возможности принятия органами местного самоуправления произвольных решений; реализуя полномочие по установлению размера платы за ремонт и содержание жилого помещения, органы местного самоуправления должны руководствоваться критериями пропорциональности и соразмерности с целью соблюдения баланса интересов участников жилищных правоотношений (Определение от 22 марта 2011 года № 357-О-О).

Из этого следует, что обжалуемое заявительницей правовое регулирование принято Исполнительным комитетом муниципального образования города Казани в рамках реализации приведенных норм федерального законодательства и, исходя из своей правовой природы, распространяется на собственников помещений в многоквартирных домах, которые не воспользовались своим правом на самостоятельное принятие решения о выборе способа управления многоквартирным домом и (или) об установлении размера платы за содержание жилых помещений по видам услуг.

Тем самым оспариваемые гражданкой Р.Х. Кашаповой нормы сами по себе не предусматривают ограничений в реализации собственниками помещений в многоквартирных домах права по принятию на общем собрании собственников решения об установлении размера платы за содержание жилого помещения, условиях и порядке ее внесения и, следовательно, не содержат неопределенности в вопросе их соответствия Конституции Республики Татарстан. В связи с этим согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Та-

тарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба заявительницы не является допустимой.

Кроме того, исходя из содержания пункта 64 Правил предоставления коммунальных услуг собственникам и пользователям помещений в многоквартирных домах и жилых домов, утвержденных постановлением Правительства Российской Федерации от 6 мая 2011 года № 354, собственники жилых помещений в многоквартирном доме при наличии договора о предоставлении коммунальных услуг, заключенного с управляющей организацией, вправе вносить плату за такие услуги либо непосредственно в ресурсоснабжающую организацию, которая продает коммунальный ресурс управляющей организации, либо через платежных агентов или банковских платежных агентов, указанных ресурсоснабжающей организацией, в том случае, когда решение о переходе на такой способ расчетов и о дате перехода принято общим собранием собственников помещений в многоквартирном доме, членов товарищества или кооператива.

Однако исследование и разрешение вопросов об обоснованности размеров тарифов, применяемых при расчете платы за содержание жилых помещений, и основаниях их применения, а также о том, проводилось ли общее собрание собственников рассматриваемого многоквартирного дома, на котором были установлены размер платы за содержание жилых помещений и порядок ее внесения, не относятся к компетенции Конституционного суда Республики Татарстан, поскольку в силу части девятой статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционный суд Республики Татарстан решает исключительно вопросы права и при осуществлении конституционного судопроизводства воздерживается от установления и исследования фактических обстоятельств во всех случаях, когда это входит в компетенцию других судов или иных органов государственной власти Республики Татарстан.

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Р.Х. Кашаповой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 2 приложения № 1 и пунктом 2 приложения № 2 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год», поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями не является допустимой, а разрешение поставленных

заявительницей вопросов Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Р.Х. Кашаповой и в Исполнительный комитет муниципального образования города Казани.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 11-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

**«2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымтаның 2 пункты һәм 2 нче кушымтаның 2 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Р.Х. Кашапова шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2016 ел
6 июнь
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Р.Х. Кашапова шикаятен алдан өйрәнгән судья А.Р. Шакараев бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**а ч ы к л а д ы :**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Р.Х. Кашапова «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымтаның 2 пункты һәм 2 нче кушымтаның 2 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте. Әлеге карар белән социаль наем килешүе һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак биналарга наем килешүе буенча торак биналарны яллаучылар, шулай ук күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак биналарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күп фатирлы йортлардагы биналар хуҗалары өчен торак биналарны карап тотуга түләү күләме хезмәт күрсәтү төрләре буенча 2016 елның 1 гыйнварыннан алып 2016 елның 30 июненә кадәр (1 нче кушымта) һәм 2016 елның 1 июленнән алып 2016 елның 31 декабренә кадәр (2 нче кушымта) расланган һәм гамәлгә кертелгән. Дәгъвалана торган нигезләмәләр белән күп фатирлы йорт белән идарә итү өчен тариф айга торак бинаның гомуми мәйданының 1 кв. метрыннан 2,70 сум тәшкил итә дип билгеләнгән.

Шикаятьтән, аңа өстәмәдән һәм шуларга кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче — 2016 елдан «Жилищник-4» ИК идарәсендәге (элегрәк йорт «Азино-1» торак милекчеләре ширкәте идарәсендә булган) күп фатирлы йорттагы торак бина хуҗасы. Гражданка Р.Х. Кашапова күрсәткәнчә, дәгъвалана торган нормалар нигезендә ул

агымдагы елда күп фатирлы йорт белән идарә итү өчен айга торак бинаның гомуми мәйданының 1 кв. метрыннан 2,70 сум түләргә тиеш. Аның фикеренчә, әлеге бәягә «Казан шәһәренең бердәм исәп-хисап үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба — «Казан шәһәренең БИХҮ» ҖЧҖ) хезмәтләре өчен түләү кергән, аның күләме аларның күп фатирлы йортлары өчен айга торак бинаның гомуми мәйданының 1 кв. метрыннан 1,23 сум тәшкил итә.

Мөрәҗәгать итүче уйлавынча, «Казан шәһәренең БИХҮ» ҖЧҖның арадашчы хезмәтләреннән башка, күп фатирлы йорт белән идарә итү өчен ул шактый азрак түләр иде. Шуңа бәйле рәвештә ул Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына мөрәҗәгать иткән. Аның мөрәҗәгатенә алынган җавапның эчтәлегеннән аңлашылганча, «Казан шәһәренең БИХҮ» ҖЧҖ идарәче оешмалар, хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр һәм биналар хуҗалары арасында коммуналь һәм башка хезмәтләр өчен исәп-хисаплар башкару тәртибенә кагылышлы законнарны максималь тулы дәрәҗәдә үтәү максатында оештырылган, ә «Күп фатирлы йорт белән идарә итү» хезмәте буенча җыела торган керемнәр исәп приборлары күрсәткечләрен эшкәртүгә, счет-фактураларны булдыру һәм бастыруга, түләүләр турындагы мәгълүматны гомумиләштерүгә, гражданнарны исәпкә кую өчен документлар әзерләүгә, коммуналь предприятиеләр белән шартнамәле мөнәсәбәтләрне тәэмин итүгә, претензия эшенә һәм башкаларга тотыла.

Ләкин мөрәҗәгать итүче «Казан шәһәренең БИХҮ» ҖЧҖның арадашчы функцияләренә бернинди дә ихтыяҗ юк дип саный, чөнки гамәлдәге федераль законнар нигезендә гражданнар торак биналарны карап тоту һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүне турыдан-туры идарәче оешмага түләү агенты катнашыннан тыш кертергә хокуклы.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Р.Х. Кашапова Татарстан Республикасы Конституция судыннан «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымтаның 2 пунктын һәм 2 нче кушымтаның 2 пунктын алар күп фатирлы йорт белән идарә итү тарифына «Казан шәһәренең БИХҮ» ҖЧҖны карап тотуны керткән дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 49, 51 һәм 55 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе Торак кодексының 154 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты нигезендә торак бина һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә күп фатирлы йорттагы бина хуҗасы өчен хезмәтләр, күп фатирлы йорт белән идарә итү өчен түләүне үз эченә алган торак бинаны карап тоткан өчен түләү керә. Күрсәтелгән Кодексның 156 статьясындагы 7 һәм 8 өлешләре мәгънәсеннән чыгып, торак бинаны карап тоткан һәм аңа ремонт ясаган өчен түләү

күләме торак биналар һәм торак булмаган биналар хуҗалары өчен күп фатирлы йорттагы биналар хуҗаларының гомуми җыелышында яки торак хуҗалары ширкәтенең идарә органнары яисә торак кооперативының идарә органнары яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативының идарә органнары тарафыннан билгеләнә. Шул ук вакытта, күп фатирлы йорттагы бина хуҗаларының торак өлкәсендә бәяләр билгеләүне җайга салуга хокукларының өстенлеген законнар дәрәҗәсендә беркетеп, Россия Федерациясе Торак кодексы 156 статьясының 3 өлеше һәм 158 статьясының 4 өлеше нигезендә шуны күздә тота: әгәр торак биналар хуҗалары күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән һәм (яки) үзләренең гомуми җыелышында торак бинаны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән булсалар, мондый күләм җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә.

Россия Федерациясе Конституция Суды күрсәткәнчә, Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше нигезендә җирле үзидарә органнарына күп фатирлы йортта торак бинаны карап тоткан һәм аңа ремонт ясаган өчен түләү күләмен билгеләү буенча вәкаләт бирү күп фатирлы йорттагы биналар хуҗалары тарафыннан әлеге түләүне мөстәкыйль рәвештә билгеләү хокукын тормышка ашыруга комачауламый, чөнки җирле үзидарә органнарының күрсәтелгән вәкаләтен гамәлгә ашыру күп фатирлы йорттагы биналар хуҗаларының тиешле ихтыяр белдерүләренең булмавы белән аңлатыла. Дәгъвалана торган закон нигезләмәсе торак-коммуналь хуҗалыгының тиешле рәвештә эшләп торуын тәэмин итүгә юнәлгән, бу исә күп фатирлы йорттагы биналар хуҗаларының да, торакка кагылышлы хокук мөнәсәбәтләрендә башка торучыларның да мәнфәгатьләренә туры килә; Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше җирле үзидарә органнары тарафыннан ирекле карарлар кабул ителү мөмкинлеген күздә тотмый; торак бинага ремонт ясаган һәм аны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү вәкаләтен гамәлгә ашырып, җирле үзидарә органнары, торакка кагылышлы хокук мөнәсәбәтләрендә торучылар мәнфәгатьләренең балансын саклау максатында, пропорциональлек һәм ярашлылык критерийларына таянырга тиеш (2011 елның 22 мартындагы 357-О-О номерлы Билгеләмә).

Моннан чыгып, мөрәҗәгать итүче дәгъва белдерә торган хокукый җайга салу Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан федераль законнарның китерелгән нормаларын гамәлгә ашыру кысаларында кабул ителгән һәм, үзенең хокукый табигатеннән чыгып, күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) торак биналарны карап тоткан өчен хезмәт күрсәтү төрләре буенча түләү күләмен билгеләү хакында мөстәкыйль карар кабул итүгә хокукларыннан файдаланмаган күп фатирлы йортлардагы биналар хуҗаларына кагыла.

Шул рәвешле гражданка Р.Х. Кашапова дәгъва белдерә торган нормалар үзеннән-үзе күп фатирлы йортлардагы биналар хуҗалары тарафыннан үзләренең гомуми җыелышында торак

бинаны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү, аны кертү шартлары һәм тәртибе турында карар кабул итү хокукын гамәлгә ашыруда чикләүләр күздә тотмыйлар һәм, димәк, аларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Моннан тыш, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары белән расланган Күп фатирлы йортлар һәм торак йортлардагы биналар хуҗаларына һәм кулланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләренең 64 пункты эчтәлегеннән чыгып, күп фатирлы йорттагы торак биналар хуҗалары, коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында идарәче оешма белән төзелгән шартнамә булганда, андый хезмәтләр өчен түләүне идарәче оешмага коммуналь ресурсны сата торган ресурслар белән тәэмин итүче оешмага турыдан-туры яисә ресурслар белән тәэмин итүче оешма күрсәткән түләү агентлары яки банк түләү агентлары аша андый исәп-хисап ысулына күчү турында һәм күчү датасы хакында карар күп фатирлы йорттагы биналар хуҗалары, ширкәт яки кооператив әгъзаларының гомуми җыелышында кабул ителгән очракта кертергә хокуклы.

Ләкин торак биналарны карап тоткан өчен түләүне хисаплаганда кулланыла торган тарифлар күләменең нигезле булу-булмавы һәм аларны куллану нигезләре турында, шулай ук карала торган күп фатирлы йорттагы хуҗаларның торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләмен һәм аны кертү тәртибен билгеләгән гомуми җыелышының үткәрелгән булу-булмавы хакындагы мәсьәләләрне тикшерү һәм хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды компетенциясенә керми, чөнки «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары компетенциясенә кергән барлык очракларда факттагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак бина-

ларны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымтаның 2 пункты һәм 2 нче кушымтаның 2 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Р.Х. Кашапова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки билгеләнгән таләпләр нигезендә шикаять карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Р.Х. Кашаповага һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 11-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.А. Сидлярук на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 1 статьи 2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан»**

8 июля
2016 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Р.Ф. Гафиятуллина, проводившего на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Г.А. Сидлярук,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Г.А. Сидлярук с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 1 статьи 2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан».

Оспариваемый пункт 1 статьи 2 указанного Закона Республики Татарстан определяет категории граждан, которым, в том числе детям-сиротам, детям, оставшимся без попечения родителей, лицам из числа детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, гражданам, имеющим детей в возрасте до восемнадцати лет, семьям, имеющим детей-инвалидов, страдающих тяжелыми формами хронических заболеваний, предоставляются меры государственной адресной социальной поддержки.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, гражданка Г.А. Сидлярук, являющаяся матерью двоих несовершеннолетних детей, считает, что в указанный перечень категорий граждан необоснованно не включены учащиеся и студенты образовательных учреждений города Казани. В целях предоставления для учащихся и студентов образовательных учреждений города Казани льготных проездных билетов она неоднократно обращалась в Исполнительный комитет муниципального образования города Казани, к депутатам Государственного Совета Республики Татарстан, а также в иные органы государственной власти Республики Татарстан.

В обоснование своей позиции заявительница ссылается на то, что действовавшее до принятия Федерального закона от 22 августа 2004 года № 122-ФЗ «О внесении изменений в законодательные акты Российской Федерации и признании утратившими силу некоторых законодательных актов Российской Федерации в связи с принятием федеральных законов «О внесении изменений и дополнений в Федеральный закон «Об общих принципах организации законодательных (представительных) и исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации» и

«Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации» законодательство предусматривало возможность предоставления школьных и студенческих проездных билетов всем категориям учащихся и студентов независимо от их имущественного и социального положения.

На основании изложенного гражданка Г.А. Сидлярук просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункт 1 статьи 2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» не соответствующим Конституции Республики Татарстан, ее статьям 27 (часть первая), 28 (части первая и вторая), 29 (части первая и вторая), 30, 32 и 38 (часть первая).

2. Федеральным законом от 6 октября 1999 года № 184-ФЗ «Об общих принципах организации законодательных (представительных) и исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации» (в редакции Федерального закона от 21 декабря 2013 года № 371-ФЗ) предусмотрено, что органы государственной власти субъекта Российской Федерации вправе устанавливать за счет средств бюджета субъекта Российской Федерации (за исключением финансовых средств, передаваемых из федерального бюджета бюджету субъекта Российской Федерации на осуществление целевых расходов) дополнительные меры социальной поддержки и социальной помощи для отдельных категорий граждан, в том числе исходя из установленных законами и иными нормативными правовыми актами субъекта Российской Федерации критериев нуждаемости, вне зависимости от наличия в федеральных законах положений, устанавливающих указанное право. Финансирование полномочий, предусмотренное данной статьей, не является обязанностью субъекта Российской Федерации, осуществляется при наличии возможности, а также не является основанием для выделения дополнительных средств из федерального бюджета (части третья и четвёртая статьи 26.3-1).

В Республике Татарстан категории граждан, которым предоставляются меры адресной социальной поддержки, а также конкретные объемы и формы их предоставления определены в Законе Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан». Предусматривая дополнительные меры социальной поддержки отдельным категориям граждан, республиканский законодатель был вправе самостоятельно определить условия и порядок их предоставления, а также категории граждан, которым они предоставляются. Применительно к детям, согласно взаимосвязанным положениям статьи 2 и пункта 8 статьи 8 указанного Закона Республики Татарстан, меры государственной адресной социальной поддержки, к числу которых относится и субсидия на проезд, предоставляются детям-сиротам, детям, оставшимся без попечения родителей, лицам из числа детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, семьям, имеющим трех и более детей в возрасте до восемнадцати лет.

Организационно-правовой механизм реализации права на

предоставление данной меры социальной поддержки, основания и критерии ее получения установлены Порядком предоставления единого месячного социального проездного билета и единого месячного детского социального проездного билета в Республике Татарстан, утвержденным постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 7 апреля 2005 года № 161 «Об утверждении Порядка предоставления единого месячного социального проездного билета и единого месячного детского социального проездного билета в Республике Татарстан». Пункт 3 указанного Порядка был предметом рассмотрения Конституционного суда Республики Татарстан, который указал, что по своему целевому назначению рассматриваемое правовое регулирование принято во исполнение Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан», не устанавливает каких-либо дополнительных необоснованных условий приобретения единого месячного социального проездного билета и единого месячного детского социального проездного билета (определение от 21 марта 2016 года № 4-О).

Таким образом, установленное оспариваемым Законом Республики Татарстан правовое регулирование носит целевой характер и направлено на поддержку материального благополучия отдельных категорий граждан. Правовая природа данных субсидий обусловлена тем, что они выступают в качестве дополнительных мер социальной поддержки и финансируются в полном объёме за счёт средств бюджета Республики Татарстан. Это означает, что основания и условия их предоставления определяются республикой самостоятельно, с учетом социально-экономического развития, финансовых и иных материальных возможностей. Расширение перечня льготных категорий граждан, которым предоставлено право льготного проезда, относится к компетенции законодательных органов субъектов Российской Федерации при наличии соответствующей бюджетной компенсации убытков от перевозки данных категорий граждан.

С учётом изложенного обжалуемый гражданкой Г.А Сидлярук пункт 1 статьи 2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» не содержит неопределенности в вопросе о его соответствии Конституции Республики Татарстан и, следовательно, согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба заявительницы не является допустимой. Разрешение же поставленного ею вопроса о распространении права на приобретение единого месячного социального проездного билета и единого месячного детского социального проездного билета на всех учащихся и студентов в Республике Татарстан предполагает внесение изменений в действующее законодательство, что входит в компетенцию законодателя и не относится к полномочиям Конституционного суда Республики Татарстан, как они определены в статье 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного, руководствуясь частью пятой статьи 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.А. Сидлярук на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 1 статьи 2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан», поскольку она не отвечает требованиям Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», в соответствии с которыми жалоба признается допустимой, и разрешение поставленных в ней вопросов неподведомственно Конституционному суду Республики Татарстан.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Г.А. Сидлярук и в Государственный Совет Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 12-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.А. Сидлярук шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2016 ел
8 июль
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Г.А. Сидлярук шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Ф. Гафиятуллин бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.А. Сидлярук «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы дәгъвалана торган 1 пункты шул исәптән ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар исәбеннән булган затларга, унсигез яшькә кадәрге балалары булган гражданнарга, авыр хроник авырулардан интегүче инвалид балалары булган гаиләләргә дәүләт адреслы социаль ярдәм чаралары күрсәтелә торган гражданнар категорияләрен билгели.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, балигъ булмаган ике бала анасы булган гражданка Г.А. Сидлярук күрсәтелгән гражданнар категорияләре исемлегенә Казан шәһәренең белем бирү учреждениеләре укучылары һәм студентлары нигезсез кертелмәгән дип саный. Казан шәһәренең белем бирү учреждениеләре укучылары һәм студентларына ташламалы юл йөрү билетларын бирү максатында ул берничә тапкыр Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнарына мөрәҗәгать иткән.

Үз позициясен нигезләп, мөрәҗәгать итүче «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә җирле

үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2004 елның 22 августындагы 122-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителгәнчегә кадәр гамәлдә булган законнарның укучы һәм студентларның юл йөрү билетларын укучы һәм студентларның барлык категорияләренә, аларның мөлкәти һәм социаль хәленә карамастан, бирү мөмкинлеген күздә тотканлыгын күрсәтә.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Г.А. Сидлярук Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенә, аның 27 (беренче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче һәм икенче өлешләр), 30, 32 һәм 38 (беренче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законда (2013 елның 21 декабрендәге 371-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) каралганча, Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары хисабына (федераль бюджеттан максатчан чыгымнарны гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъекты бюджетына тапшырыла торган финанс чараларыннан тыш) гражданнарның аерым категорияләре өчен социаль ярдәм күрсәтүнең һәм социаль булышуның өстәмә чараларын шул исәптән Россия Федерациясе субъекты законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән мохтаҗлык критерийларыннан чыгып билгеләргә хокуклы, бу федераль законнарда әлеге хокукны билгели торган нигезләмәләрнең булу-булмавына бәйле түгел. Әлеге статьяда каралган вәкаләтләрне финанслау Россия Федерациясе субъектының бурычы булып тормый, мөмкинлек булганда гамәлгә ашырыла, шулай ук федераль бюджеттан өстәмә акча бүлеп бирү өчен нигез булып тормый (26.3-1 статьяның өченче һәм дүртенче өлешләре).

Татарстан Республикасында адреслы социаль ярдәм чаралары күрсәтелә торган гражданнар категорияләре, шулай ук аларны күрсәтүнең конкрет күләмнәре һәм рәвешләре «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән. Гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чараларын күздә тотып, республика закон чыгаручысы аларны күрсәтүнең шартларын һәм тәртибен, шулай ук алар күрсәтелә торган гражданнар категорияләрен мөстәкыйль билгеләргә хокуклы булган. Аталган Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы белән үзара бәйләнештә 8 статьясының 8 пункты нигезләмәләре буенча балаларга карата дәүләт адреслы социаль ярдәм чаралары, алар

исәбенә транспортта йөрү өчен субсидия дә керә, ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар исәбеннән булган затларга, унсигез яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк балалары булган гаиләләргә күрсәтелә.

Әлеге социаль ярдәм чарасын күрсәтүгә хокукны гамәлгә ашыруның оештыру-хокукый механизмы, аны алуның нигезләре һәм критерийлары «Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 7 апрелендәге 161 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибе белән билгеләнгән. Күрсәтелгән Тәртипнең 3 пункты Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булган иде, ул күрсәткәнчә, үзенең максатчан билгеләнеше буенча карала торган хокукый җайга салу «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән кабул ителгән, транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет алуның нинди дә булса өстәмә нигезсез шартларын билгеләми (2016 елның 21 мартындагы 4-О номерлы билгеләмә).

Шулай итеп, дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән хокукый җайга салу максатчан төсмергә ия һәм гражданнарның аерым категорияләренең матди уңайлыкларына ярдәм итүгә юнәлдерелгән. Әлеге субсидияләрнең хокукый табигате тагын шуңа да бәйле, алар өстәмә социаль ярдәм чаралары булып торалар һәм тулысынча Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финансланалар. Бу аларны бирү нигезләре һәм шартлары социаль-икътисади үсеш, финанс һәм башка матди мөмкинлекләрне исәпкә алып, республика тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә дигәнне аңлата. Ташламалы юл йөрү хокукы бирелгән гражданнарның ташламалы категорияләре исемлеген киңәйтү, әлеге гражданнар категорияләрен йөртү чыгымнарының тиешле бюджет компенсациясе булганда, Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару органнары компетенциясенә керә.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы гражданка Г.А. Сидлярук тарафыннан дәгъвалана торган 1 пунктының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк һәм, димәк, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый. Транспортта йөрү өчен бердәм айлык со-

циаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет алуга хокукны Татарстан Республикасындагы барлык укучыларга һәм студентларга да кагылдыру турындагы ул куйган мәсьәләне хәл итү гамәлдәге законнарга үзгәрешләр кертүне күздә тота, бу исә закон чыгаручы компетенциясенә керә һәм Татарстан Республикасы Конституция судының «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгән вәкаләтләренә карамый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче өлешенә, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.А. Сидлярук шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының шикаять бирелергә мөмкин дигән таләпләренә җавап бирми һәм анда куелган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.
2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.
3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.А. Сидлярукка һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.
4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 12-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.П. Караблевой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 3.1 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан»**

8 июля
2016 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Р.А. Сахиевой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Г.П. Караблевой,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Г.П. Караблева с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 3.1 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан» (далее также — Положение). Данный пункт, в частности, устанавливает формулу, по которой рассчитывается размер субсидии-льготы отдельному члену семьи, имеющему право на указанную субсидию. При этом объем потребления каждой жилищной и коммунальной услуги определяется исходя из общего расхода семьи, в равной мере приходящегося на каждого члена семьи.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, гражданка Г.П. Караблева на основании Федерального закона от 24 ноября 1995 года № 181-ФЗ «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации» является получателем компенсации расходов на оплату жилых помещений и коммунальных услуг в виде субсидии-льготы. Она отмечает, что вместе со своим супругом была лишена половины субсидии-льготы по причине неопределенности величин, примененных в формуле, по которой рассчитывался размер субсидии-льготы отдельному члену семьи, имеющему право на данную субсидию.

Заявительница полагает, что на основании оспариваемой нормы компенсация расходов на оплату жилых помещений и коммунальных услуг выплачивается инвалидам только на их долю. В связи с этим, по ее мнению, инвалиды, проживающие совместно с другими членами семьи, оказываются в неравном положении с

одинокими инвалидами, детьми-инвалидами и некоторыми иными категориями граждан.

На основании изложенного гражданка Г.П. Караблева просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункт 3.1 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан», не соответствующим статьям 27 (часть первая), 28 (части первая и вторая), 29 (части первая и вторая) и 30 Конституции Республики Татарстан.

2. В соответствии с частью 1 статьи 160 Жилищного кодекса Российской Федерации отдельным категориям граждан в порядке и на условиях, которые установлены федеральными законами, законами субъектов Российской Федерации и нормативными правовыми актами органов местного самоуправления, могут предоставляться компенсации расходов на оплату жилых помещений и коммунальных услуг за счет средств соответствующих бюджетов.

Право на предоставление компенсации расходов на оплату жилых помещений и коммунальных услуг инвалидам и семьям, имеющим детей-инвалидов, в размере 50 процентов закреплено в части тринадцатой статьи 17 Федерального закона от 24 ноября 1995 года № 181-ФЗ «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации». При этом в силу положений статьи 28.2 данного Федерального закона полномочия по предоставлению указанных мер социальной поддержки передаются органам государственной власти субъектов Российской Федерации, средства на реализацию которых предусматриваются в федеральном бюджете в виде субвенций; объем субвенций из федерального бюджета бюджетам субъектов Российской Федерации определяется по оплате жилого помещения и коммунальных услуг исходя из числа лиц, имеющих право на данные меры социальной поддержки.

В соответствии с письмами Министерства регионального развития Российской Федерации от 25 декабря 2006 года № 14713-РМ/07 и Министерства труда и социальной защиты Российской Федерации от 7 сентября 2012 года № 12-3/10/2-1570 меры социальной поддержки по оплате жилого помещения и коммунальных услуг, предусмотренные в статье 17 Федерального закона «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации», предоставляются одиноко проживающим инвалидам на оплату всей занимаемой площади и всего объема потребленных коммунальных услуг, а инвалидам, проживающим совместно с другими членами семьи, только на долю жилого помещения, приходящуюся на инвалида.

На основании вышеназванных федеральных норм Кабинет Министров Республики Татарстан постановлением от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан» утвердил Положение о порядке и условиях

предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан. Оспариваемый заявительницей пункт 3.1 Положения направлен на реализацию инвалидами права на получение рассматриваемой субсидии-льготы и по своей правовой природе определяет лишь конкретный механизм ее расчета и сам по себе не предполагает дополнительного регулирования предоставления такой меры социальной поддержки, отличающегося от требований, установленных федеральным законодательством.

Из этого следует, что проверка конституционности обжалуемого гражданкой Г.П. Караблевой нормативного положения фактически означала бы оценку названных норм федерального законодательства на их соответствие Конституции Республики Татарстан, что в силу части четвертой статьи 109 Конституции Республики Татарстан и статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не входит в компетенцию Конституционного суда Республики Татарстан.

На основании изложенного, руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.П. Караблевой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 3.1 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан», поскольку разрешение поставленных заявительницей вопросов неподведомственно Конституционному суду Республики Татарстан.
2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.
3. Копию настоящего Определения направить гражданке Г.П. Караблевой и в Кабинет Министров Республики Татарстан.
4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 13-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

**«Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 3.1 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.П. Караблева шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2016 ел
8 июль
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Г.П. Караблева шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.П. Караблева «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең (алга таба шулай ук — Нигезләмә) 3.1 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте. Әлеге пункт, аерым алганда, ташлама-субсидия алуга хокуклы аерым гаилә әгъзасына күрсәтелгән субсидия зурлыгын исәпли торган формуланы билгели. Шул ук вакытта һәр торак һәм коммуналь хезмәтне файдалану күләме гаиләнең гомуми файдалануыннан чыгып, гаиләнең һәр әгъзасына тигез итеп билгеләнә.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка Г.П. Караблева — «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә торак урыннар һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнарына ташлама-субсидия рәвешендә компенсация алучы. Ул билгеләгәнчә, ташлама-субсидия алуга хокуклы аерым гаилә әгъзасына әлеге субсидия күләме исәпләнгән формулада кулланылган зурлыкларның билгесезлеге сәбәпле, ире белән ташлама-субсидиянең яртысыннан мәхрүм калган.

Мөрәҗәгать итүче уйлавынча, дәгъва белдерелә торган норма нигезендә торак урыннар һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү

чыгымнарына компенсация инвалидларга аларның өлешенә генә түләнә. Шуңа бәйле рәвештә, аның фикеренчә, башка гаилә әгъзалары белән бергә яшәүче инвалидлар ялгыз инвалидлар, инвалид балалар һәм гражданнарның кайбер башка категорияләре белән тигез булмаган хәлдә булып чыгалар.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Г.П. Караблева Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 3.1 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенең 27 (беренче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче һәм икенче өлешләр) һәм 30 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе Торак кодексының 160 статьясындагы 1 өлеше нигезендә гражданнарның аерым категорияләренә федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм җирле үзидарә органнары норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда торак урыннар һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнарына компенсацияләр тиешле бюджетлар акчасы хисабына бирелергә мөмкин.

Инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә торак урыннар һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнарына 50 процент күләмендә компенсация бирүгә хокук «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы унөченче өлешендә беркетелгән. Шул ук вакытта әлеге Федераль законның 28.2 статьясы нигезләмәләре буенча аталган социаль ярдәм чараларын күрсәтү вәкаләтләре Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырыла, аларны гамәлгә ашыруга акча федераль бюджетта субвенцияләр рәвешендә карала; федераль бюджетта Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына каралган субвенцияләр күләме торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча әлеге социаль ярдәм чараларына хокукы булган затлар саныннан чыгып билгеләнә.

Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгының 2006 елның 25 декабрендәге 14713-РМ/07 номерлы һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 7 сентябрендәге 12-3/10/2-1570 номерлы хатлары нигезендә «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында»гы Федераль законның 17 статьясында каралган торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары ялгыз яшәүче инвалидларга бөтен торак мәйдан һәм кулланылган коммуналь хезмәтләрнең бөтен күләме өчен, ә башка гаилә әгъзалары белән бергә яшәүче инвалидларга бары тик инвалидка караучы торак урын өлешенә генә түләүгә бирелә.

Югарыда аталган федераль нормалар нигезендә Татарстан Рес-

публикасы Министрлар Кабинеты «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслаган. Нигезләмәнең мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган 3.1 пункты инвалидларның карала торган ташлама-субсидияне алуга хокукны гамәлгә ашыруына юнәлдерелгән һәм үзенең хокукый табигате буенча аны исәпләүнең конкрет механизмын гына билгели һәм үзеннән-үзе федераль законнар белән билгеләнгән таләпләрдән аерыла торган андый социаль ярдәм чарасын күрсәтүне өстәмә җайга салуны күздә тотмый.

Моннан чыгып, гражданка Г.П. Караблева тарафыннан дәгъвалана торган норматив нигезләмәнең конституциячеллеген тикшерү чынлыкта аталган федераль законнар нормаларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәвенә бәя бирүне аңлатыр иде, бу исә Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясындагы дүртенче өлеше һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 3.1 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.П. Караблева шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.
2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.
3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.П. Караблевага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.
4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 13-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.П. Караблевой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем четвертым пункта 2.4 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан»**

15 июля 2016 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Р.Ф. Гафиятуллина, Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Л.В. Кузьминой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Г.П. Караблевой,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Г.П. Караблева с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем четвертым пункта 2.4 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан» (далее также —Положение).

Оспариваемой нормой установлено, что предоставление субсидии-льготы приостанавливается в случае неуплаты получателем текущих платежей за жилое помещение и коммунальные услуги за период свыше 3 месяцев подряд до момента начала погашения образовавшейся задолженности или при заключении и (или) выполнении получателем соглашения по ее погашению.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, заявительнице было приостановлено предоставление субсидии-льготы на оплату жилья и коммунальных услуг в связи с неуплатой текущих платежей за жилое помещение и коммунальные услуги за период свыше 3 месяцев подряд. Впоследствии гражданка Г.П. Караблева начала погашать данную задолженность, за исключением платы за одну из услуг, поскольку полагала, что она не оказывается надлежащим образом.

Заявительница обратилась в отделение № 8 Республиканского центра материальной помощи Альметьевского муниципального района Республики Татарстан с заявлением о возобновлении выплаты субсидии-льготы, однако в удовлетворении данного требования ей было отказано и сообщено, что предоставление субсидии-льготы приостановлено с августа 2014 года по причине задолженности

свыше 3 месяцев перед ООО «Русло» до момента начала погашения образовавшейся задолженности, после чего субсидия-льгота будет выплачена в полном объеме с момента приостановления.

Гражданка Г.П. Караблева полагает, что моментом начала погашения задолженности, исходя из содержания обжалуемой нормы, должно являться внесение любой суммы в счет погашения задолженности, однако, по мнению заявительницы, правоприменительные органы под моментом начала погашения задолженности понимают полное ее погашение, что противоречит тексту оспариваемой нормы.

На основании изложенного гражданка Г.П. Караблева просит Конституционный суд Республики Татарстан признать абзац четвертый пункта 2.4 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан», не соответствующим статьям 28 (часть первая) и 54 (часть первая) Конституции Республики Татарстан.

2. Согласно статье 159 Жилищного кодекса Российской Федерации субсидии на оплату жилого помещения и коммунальных услуг предоставляются гражданам при отсутствии у них задолженности по оплате жилых помещений и коммунальных услуг или при заключении и (или) выполнении гражданами соглашений по ее погашению (часть 5); условия приостановки и прекращения предоставления субсидий устанавливаются Правительством Российской Федерации (часть 7). В развитие указанных нормативных положений постановлением Правительства Российской Федерации от 14 декабря 2005 года № 761 утверждены Правила предоставления субсидий на оплату жилого помещения и коммунальных услуг, пунктом 6 которых также установлено, что субсидии предоставляются гражданам при отсутствии у них задолженности по оплате жилого помещения и коммунальных услуг или при заключении и (или) выполнении гражданами соглашений по ее погашению.

Следовательно, одним из условий предоставления гражданам субсидий является отсутствие у них задолженности по оплате жилых помещений и коммунальных услуг или заключение и (или) выполнение гражданами соглашений по ее погашению, поскольку в силу положений статьи 153 Жилищного кодекса Российской Федерации граждане обязаны своевременно и полностью вносить плату за жилое помещение и коммунальные услуги.

На основании приведенных федеральных норм Кабинет Министров Республики Татарстан регламентировал в пункте 2.4 Положения процедуру возобновления выплаты субсидии-льготы, предоставление которой было приостановлено в связи с неуплатой текущих платежей за жилое помещение и коммунальные услуги. При этом, реализуя свои дискреционные полномочия, Кабинет Министров Республики Татарстан установил, что выплата субсидии-льготы возобновляется именно с момента начала погашения образовавшейся задолженности. Тем самым данное правовое регу-

лирование не только по своей сути выступает в качестве дополнительной меры социальной защиты, но и само по себе не допускает возможности иной трактовки оспариваемой нормы в правоприменительной практике.

Таким образом, обжалуемый абзац четвертый пункта 2.4 Положения не содержит неопределенности в вопросе о его соответствии Конституции Республики Татарстан и не может рассматриваться как нарушающий конституционные права и свободы человека и гражданина, в связи с чем согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба гражданки Г.П. Караблевой не является допустимой.

Разрешение же вопроса о законности и обоснованности правоприменительных решений по делу заявительницы, в том числе с точки зрения правильности применения правовых норм с учетом фактических обстоятельств, не относится к компетенции Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена статьей 109 Конституции Республики Татарстан и статьей 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктом 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.П. Караблевой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем четвертым пункта 2.4 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126 «О предоставлении субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан», поскольку она в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой, а разрешение поставленного заявительницей вопроса Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Г.П. Караблевой и в Кабинет Министров Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 14-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

**«Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.4 пунктындагы дүртенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.П. Караблева шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2016 ел
15 июль
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Р.Ф. Гафиятуллин, Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Г.П. Караблева шикаятен алдан өйрәнгән судья Л.В. Кузьмина бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.П. Караблева «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең (алга таба шулай ук — Нигезләмә) 2.4 пунктындагы дүртенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъвалана торган норма белән билгеләнгәнчә, ташлама-субсидия бирү ташлама-субсидия алучы торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен агымдагы түләүләрне җыелган бурычларны каплый башлаган вакытка кадәр тоташтан 3 айдан артык чор өчен түләмәгән очракта яки ташлама-субсидия алучы аны каплау турында килешү төзегәндә һәм (яки) үтәгәндә туктатып торыла.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүчегә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидия бирү торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен агымдагы түләүләрне тоташтан 3 айдан артык чор өчен түләмәгәнгә күрә туктатып торылган. Соңыннан гражданка Г.П. Караблева әлеге бурычын каплый башлаган, ләкин бер хезмәт өчен түләмәгән, чөнки ул тиешенчә күрсәтелми дип санаган.

Шикаять бирүче Республика матди ярдәм үзәгенең Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы 8 номерлы бүлегенә ташлама-субсидияне яңадан бирә башлау турында гариза белән мөрәҗәгать иткән, ләкин әлеге таләпне үтәүдән аңа баш тартылган һәм «Русло» ҖЧҖ алдында 3 айдан артык бурычы булу сәбәпле ташлама-субсидияне бирү 2014 елның августыннан җыелган бурычны каплый башлаган вакытка кадәр туктатып торылган, шул вакыттан соң ташлама-субсидия туктатып торылу моментыннан тулы күләмдә түләнәчәк дип хәбәр ителгән.

Гражданка Г.П. Караблева уйлавынча, дәгъвалана торган норма эчтәлегеннән чыгып, җыелган бурычны каплый башлаган вакыт булып бурычны каплау хисабына теләсә кайсы күләмдә акча кертү торырга тиеш, ләкин, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, хокук куллану органнары җыелган бурычны каплый башлаган вакыт итеп аны тулысынча каплауны аңлыйлар, бу исә дәгъвалана торган норманың текстына каршы килә.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Г.П. Караблева Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.4 пунктындагы дүртенче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче өлеш) һәм 54 (беренче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе Торак кодексының 159 статьясы нигезендә торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр гражданнарга торак урыннар һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычлары булмаганда яисә гражданнар аларны каплау турындагы килешүләр төзегәндә һәм (яисә) үтәгәндә бирелә (5 өлеш); субсидияләр бирүне туктатып тору һәм туктату шартлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә (7 өлеш). Күрсәтелгән норматив нигезләмәләрне ачыклап, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 14 декабрендәге 761 номерлы карары белән Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр бирү кагыйдәләре расланган, аларның 6 пункты белән субсидияләр гражданнарга торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычлары булмаганда яисә гражданнар аларны каплау турындагы килешүләр төзегәндә һәм (яисә) үтәгәндә бирелә дип, шулай ук билгеләнгән.

Димәк, гражданнарга субсидия бирүнең бер шарты булып аларның торак урыннар һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычлары булмавы яисә гражданнарның аларны каплау турындагы килешүләр төзүе һәм (яисә) үтәве тора, чөнки Россия Федерациясе Торак кодексының 153 статьясы нигезләмәләре буенча гражданнар торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүне үз вакытында һәм тулысынча кертергә тиеш.

Китерелгән федераль нормалар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Нигезләмәнең 2.4 пунктында торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен агымдагы түләүләрне кертмәү сәбәпле бирү туктатып торылган ташлама-субсидияне яңадан бирә башлау процедурасын регламентлаштырган. Шул ук вакытта үзенең дискрецион вәкаләтләрен гамәлгә ашырып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ташлама-субсидия нәкъ менә җыелган бурычны каплый башлаган вакыттан яңадан бирелә башлый дип билгеләгән. Шул рәвешле әлеге хокукый җайга салу асылда өстәмә социаль яклау чарасы гына булып калмыйча, үзеннән-үзе дәгъвалана торган норманың хокук куллану практикасында башкача аңлатылу мөмкинлегенә дә юл куймый.

Шулай итеп, Нигезләмәнең 2.4 пунктындагы дәгъвалана торган дүртенче абзацында Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәү мәсьәләсендә билгесезлек юк һәм ул кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза торган итеп карала алмый, шуңа күрә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә гражданка Г.П. Караблеваның шикаяте карала алмый.

Мөрәҗәгать итүче эше буенча хокук куллану карарларының законлы һәм нигезле булуы турындагы мәсьәләне шул исәптән фактагы хәлләрне истә тотып хокук нормаларының дөрес кулланылышы күзлегеннән чыгып чишү Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы белән билгеләнгән компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.4 пунктындагы дүртенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.П. Караблева шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр

нигезендә ул карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.П. Караблевага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 14-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды